ЕЛГА ЙОМГАК

Татарстан Дәүләт Советының 50 нче утырышында парламентның быелгы эшчәнлегенә нәтиҗә ясадылар

> 2

ИЛ ОНЫТМЫЙ

Махсус хәрби операциядә катнашучы егетләргә кыш көне ничек ярдәм итәргә?

> 3

КИНОМЕХАНИК ТӘНЗИЛӘ

Язмыш күпме генә сынаса да, сынмый-сыгылмый ул

> 6

ХА-ХА-ХАНӘ

Булмас, димә, кызык-мызык, фототөрткеләр монда

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 186–187 (29153–29154) | Сишәмбе | 19 декабрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ӨЧЬЯКЛЫ ҺӨҖҮМ

БЕЛГЕЧЛӘР, ЯКЫН АРАДА ЯҢА ТӨРЛЕ ВИРУС ТАРАЛЫРГА МӨМКИН, ДИП КИСӘТӘ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сәламәтлек

Вируслы авырулар котырган чорга аяк бастык. Уззәккә үткән ютәл, югары температура, баш авырту... Күпләр әнә шуннан зарлана. Халык арасында уздырылган соңгы сораштыру нәтиҗәләренә ышансаң, бүген илдә эш яшендәге һәр ун кешенең берсе вируслы чирләр белән авырый.

Белгечләр, якын арада тридемия инфекциясе йоктыручылар саны да артырга мөмкин, дип фаразлый. Гади тел белән әйткәндә, аны йоктырган кеше берьюлы өч төрле вируслы авыру белән чирли ди-гән сүз. Аннан ничек сакланырга?

Белгечләр ел азагына илдә вируслы авырулар белән авыручылар саны артачагын кисәткән иде анысы. Шулай булды да. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, бер атна эчендә республикада ОРВИ йоктыручының – 22929 һәм гриппның 992 очрагы теркәлгән. Ковид та тормышыбыздан китәргә уйламый. Бер атна эчендә Татарстанда коронавирус йоктыручылар саны 33 процентка арткан. Риновирус, аденовирус, парагрипп кебек башка вируслы авырулар йоктыручылар саны да арткан.

Белгечләр якын арада берьюлы өч төрле вирус белән авыручылар саны да артырга мөмкин дип фаразлый. Тридемия дигәндә алар ковид, грипп һәм тагын берәр респиратор чир белән берьюлы авыруны күздә тота. Барысының да билгеләре, нигездә, охшаш, ә нәтиҗәләре шактый аянычлы булырга мөмкин, дип кисәтә белгечләр. Тридемия барыннан да бигрәк йөрәк-кан тамырларына, үпкәгә бәрүе белән куркыныч.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш терапевты, Республика клиник хастаханәсенең терапия клиникасы башлыгы Диана Габделганиева сүзләренә караганда, бу чир барыннан да бигрәк иммунитеты какшаган кеше өчен куркыныч.

– Кеше респиратор авыруларның һәркайсы белән аерым-аерым гына да, берничә төрле вирус белән берьюлы да авырырга мөмкин. Монда бар да иммунитетның ни дәрәҗәдә нык булуына бәйле. Әгәр да кеше яңа гына авырып терелгән, иммунитеты какшаган икән, ул яңа вирусларга каршы тора алмаячак. Нәтиҗәдә кеше алдагысы белән чагыштырганда ныграк чирләргә мөмкин, – ди табиб.

Диана Габделганиева сүзләренә караганда, быел грипп та алдагы елдагылар белән чагыштырганда мәкерлерәк. Грипп белән авырып терелүчеләр арасында йөрәге, үпкәсе зәгыйфьләнеп калучылар шактый икән.

– Вируслы чирләрдән саклану өчен прививка ясатудан да яхшысы юк. Кеше күп җыелган урыннарга битлек кимичә чыкмаска, кулларны-битләрне һәрчак юып торырга, урамнан кергәч, борын белән авызны яхшылап чайкатырга кирәк. Бүлмәләрне җилләтеп торырга да онытмагыз. ОРВИ белән авырган кеше белән аралашырга туры килсә, алда әйтелгән киңәшләрдән тыш, борынга дару тамызып куюның да артыгы булмас, – ди баш терапевт.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш инфекционисты Халит Хәертынов сүзләренә караганда, берьюлы берничә вирус белән авыру – организм өчен икеләтә зур сынау.

– Бу очракта шунысын да белеп торырга кирәк: кеше төрле төркемгә кергән чирләр белән генә берьюлы авырый ала. Шуңа күрә, мисал өчен, ОРВИ һәм ковид белән берьюлы авыру мөмкин түгел, – ди белгеч. – Грипп белән авырып терелгәч тә: "Башка йокмас инде", – дип тынычланырга ярамый. Аның белән дә кайта-кайта авырырга мөмкин. Шуңа грипп белән авырганда тулысынча терелеп бетмәгән килеш эшкә чыгарга ярамый.

Соңгы арада балалар арасында да авыручылар шактый. Казанның 10 нчы шәһәр балалар хастаханәсенең баш табибы Лилия Мөхәммәтгатова сүзләренә караганда, соңгы бер атна эчендә аларның саны кискен арта башлаган. Кичәге көн исә аеруча рекорд куйган.

– Үткән атнада безгә мөрәҗәгать итүчеләр саны акрынлап арта башлаган иде инде. Атна азагына авыручылар саны тагын да күбәйде. Дүшәмбе көнне безгә караган 34 участокның һәркайсына 20ләп мөрәҗәгать килде. Узган атна башында шундый 7–12ләп кенә кеше табиб чакыртткан иде. Әле бу – көндезгә алынган саннар гына, – ди табиб.

Авыру аяктан егучыларның күбесе – бакчага йөрүче, мәктәптә укучы балалар. Алар, нигездә, көчле ютәлдән зарлана, температуралы югары. Кубесенә ОРВИ, ОРЗ диагнозлары куелган. Грипп очраклары бармак белән генә санарлык.

– Балалар арасында авыручылар күп булса да, бу – сезонлы күренеш. Шуңа күрә ата-аналар хәвефләнмәсен иде. Баланың температурасы күтәрелә, ул башы авыртудан зарлана икән, табиб чакыртырга кирәк. Бу салкын тию генә түгел, бик күп кенә башка авырулар-ның да билгесе булырга мөмкин. Баланы үз белдегең белән дәваларга маташу куркыныч. Вируслы авырулардан саклану өчен исә коронавирус өйрәткән гади генә кагыйдәләрне истә тотарга кирәк, – ди табиб.

Өйдә генә теркибез

Быел Татарстанда җиде мең кеше «Рождение ребенка» сервисыннан файдаланган. Ул ЗАГС органнарына бармыйча гына теркәү мөмкинлеге бирә. Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе җитәкчесе Гөлшат Нигъмәтуллина әйтүенчә, бу күрсәткеч ягынннан без Россия төбәкләренең беренче дистәсенә керәбез.

Бала туура килгәндә, быел 11 айда республикада 33 меңнән артыграк нарасый дөньяга аваз салган. Бу җәһәттән Татарстан Идел буе федераль округында алдынгы урыннарда бара. Шулай да, Нигъмәтуллина сүзләренә караганда, әлеге сан узган елдагы белән чагыштырганда 0,9 процентка кимрәк. Үлем-китем күрсәткече дә 5,2 процентка азрак теркәлгән. «Якын киләчәктә Татарстанның демографик үсеш юлына чыгачагына өметләнәбез», – дигән ЗАГС идарәсе җитәкчесе. Ул шулай ук киләсе елда республикада «Утрата близкого человека» сервисын гамәлгә кертүнең күздә тотылуын әйткән. Аның сервис Дәүләт хезмәтләре порталы аша кешенең үлеен теркәү мөмкинлеге бирәчәк.

Кисәгә сукмасын чыршы

Республикада «Чыршы» профилактика чарасы башланган. Аның кысасында, ылыслы агачларны законсыз кисүчеләргә каршы көрәшү өчен, урманнарны тикшерү оештырыла. Чара 31 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк.

Урман хуҗалыгы министрлыгы искәртеп узганча, бәйрәм күркен законсыз кисү гади кешеләргә – 3–4 мең сум, вазыйфаи затларга – 20–40 мең сум, оешмаларга 200–300 мең сум күләмендәге штраф белән яный. Моннан тыш агачны кискән кеше урманга китерелгән зыянны капларга тиеш. 5 мең сум һәм аннан күбрәк күләмдә зыян салынган очракта җинаять җаваплылыгы каралган.

Закон бозучылар турында урман сагына (8-800-100-94-00), шулай ук «Урманнарны янгыннан саклау үзәге»нә (8 (843) 221-37-95) шалтыратырга мөмкин.

Сүз уңаеннан, Казанның төп чыршысы шимбә – 23 декабрьдә ачылачак. Урман сылуы Гаилә үзәге янында урнаштырыла. Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова әйтүенчә, чыршы ачылышы Гаилә елына багышланачак.

Тагын бер яңалык: чыршыларны киләсе елның 13–20 гыйнварында махсус урыннарда эшкәртүгә тапшырып булачак. Моның өчен тәүге тапкыр «Елки-палки» акциясе оештырыла.

Юбилей очышы

«Казан» халыкара аэропорты быел 5 миллион кешегә хезмәт күрсәткән. Үз тарихында тәүге тапкыр шундый күрсәткечкә ирешкән ул. «Татар-информ» хәбәренә караганда, юбилей пассажиры кичә «Nordwind Airlines» авиакомпаниясенең «Казань – Минеральные Воды» рейсына теркәү барышында билгеләнгән. Шулай итеп, Казанда яшәүче Анастасия Данилова 5 миллионынчы пассажирга әйләнгән. «Казан» аэропорты хезмәткәрләре яшь ханымга сувенирлар, бизнес-залга бушлай керү, авиакомпаниядән бушлай очуга билет тапшырганнар.

Аэропорт генераль директоры Сергей Романцов әйтүенчә, бер ел эчендә пассажирлар саны 27 процентттан күбрәккә арткан. Аның сүзләренә караганда, маршрут челтәрен киңәйтү һәм рейслар санын арттыруга бәйле бу.

Сүз уңаеннан, 2025 елда аэропортның яңа терминалын төзи башлаячаклар. Яңа бинаны һәм перронны проектлау өчен 669 миллион сум чамасы бирелгән. Аны этаплап – 2026 елга кадәр төзү күздә тотыла. Төзелеш тәмамланганнан соң, пассажирлар санының елына 6,5 миллионга җитүе көтелә.

Көйле-көйсез декабрь

Быелгы декабрь аномаль температуралар белән шаккатыруын дәвам итә. Синоптиклар мәгълүматлары буенча, республикага көчле сукыларга алмашка бик жылы һава килә. Бу араларда җепшек кар, буран, көньяк-көнбатыштан секундына 6–11 метрга кадәр җил, юлларда бозлавык көтелә. Көндезге температурада термометрның терекөмеш баганасы –1...+1 чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә –3...–5 градус.

«Туры элемтә»дән соң

Президент әйткәч

Билгеле булганча, узган атнада Россия Президенты Владимир Путин журналистлар һәм ил халкы белән аралашты. Эфирда яңгыраган һәм эфирга керми калган сораулар арасында «мөһим», «мөһим түгел» дигәннәре юклыгына басым ясады дәүләт башлыгы. Президент әйткәч, төбәкләрдә үзгәрешләр башланганмы?

Кырымда яшәүче нәни спортчылар үзләре шөгыльләнә торган спорт залына 40 елдан артык ремонт булмаудан зарланган иде. Малайларга тагын да яхшырак үрләр яулар өчен, яхшы шартлар кирәк. Путин исә, әлеге мәсьәләне аерым игътибарга алабыз, дип сөендерде. Хәер, әлеге проблеманы эфир трансляцияләнгәнче контрольгә алдылар инде. 2024 елда бинага ремонт каралган булып чыкты.

Свердловск өлкәсенең Рефтинский бистәсендәге хастаханәгә дә ремонт кирәк. Дәүләт башлыгына әнә шундый гозер белән Егор Перминов мөрәҗәгать итте. Медицина ярдәменең түбән дәрәҗәдә булуыннан зарланды ул. Хастаханәгә шунда ук төбәкнең сәламәтлек саклау министры Андрей Карлов килгән. Ул быелтыр хастаханәгә 5 миллион 800 мең сум акча бүлеп бирелүен, бу акчага бинаның бер өлешен төзекләндерүләрен һәм җиһазлар сатып алуларын әйтте. Медицина оешмасы хәзер Асбест хастаханәсенең бер өлеше булып тора икән.

Түмән – Новосибирск трассасының Омск өлкәсе аша уза торган бер өлеше бик начар хәлдә булуын, шулай ук Омск өчен халыкара дәрәҗәдәге аэропорт кирәклеген дә хәбәр иттеләр Президентка. Владимир Путин трассаның бу өлешенә игътибар итәргә һәм федераль министрлык белән аэропорт төзү мәсьәләсендә фикерләшергә вәгъдә бирде.

«Туры элемтә» барышында Путин банкларның пенсионерлардан торак-коммуналь хуҗалык өчен түләгән вакытта комиссия алмаячагын әйтте. Аның сүзләренчә, комиссия түләтү дөрес түгел.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гозерләре дә күп булды ул көнне. Әйтик, Омск өлкәсеннән бер хәрби РЭБ-глушилка кирәклеген әйтте. Владимир Путин, тикшерербез, хәл итәрбез, дип ышандырды. Омск өлкәсе губернаторы да озак көттермәде, хәрби хезмәт иткән бүлекчәгә иң замача РЭБ-комплекс биреләчәк, диде.

Президент Владимир Путин «туры элемтә» барышында «Гаилә ипотекасы» программасын озайтуны хуплавын да белдерде. 2024 елның уртасында тәмамланырга тиешле бу программа озайтылырга тиеш, дигән фикердә ул.

Иваново өлкәсенең Акишево авылы халкы су кирәк дип мөрәҗәгать итте. 57 кешелек авылда яшәүчеләр кое һәм чокыр суларыннан гына файдаланып көн күрә икән. Соңрак Иваново өлкәсе хакимияте бу мәсьәләне хәл итәргә вәгъдә бирде.

Сан

Барлык «туры элемтә» һәм еллык матбугат конференцияләрен исәпкә алсак, дәүләт башлыгы туры эфирда **123** сәгатьтән артык вакыт үткәргән, халыктан һәм журналистлардан килеп ирешкән **2** меңгә якын сорауга җавап биргән.

Сүзгә-сүз

Наталья КОСТЕНКО, Россия Дәүләт Думасының Туризм буенча комитет рәисе урынбасары:

Тау чаңгысында шуа торган урыннарда ял итүчеләр өчен махсус иминиятләштерү кертергә кирәк. Тауда чаңгы шуганда имгәнүчеләр бик күп. Ял итү базасы хуҗалары исә аларның барысын да контрольдә тотып бетерә алмый. Анда эшләүче тренерларның квалификациясе ягын да кайгыртырга кирәк. Юкса бүген мондый ял итү урыннарында теләсә кем тренер булып эшли ала.

(«Парламентская газета» басмасыннан)

«МӘДӘНИЯТ» ИЛКҮЛӘМ ПРОЕКТЫ

ТӨЗЕЛГӘН ЯИСӘ ТӨЗЕКЛӘНДЕРЕЛГӘН – **1400** МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ

Модульле китапханә ачылган – 1056 (ел азагына – 1100)

Балалар сәнгать мәктәпләре реконструкцияләнгән – 650

Автоклублар – 400

*2019–2024 ел максатлары

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ПРОЦЕНТ СТАВКАЛАРЫ ҺӘЛАКӘТКӘ ИЛТӘ

Үткән атнада Бөтендөнья банкы җитәкчесе: «Озакка сузылган югары процент ставкалары күпчелек илләр өчен һәлакәткә илтә торган нәтиҗәгә ия булачак», – дип белдерде. Дистә еллар буена АКШ һәм Кытайдан бурычка акча алып яшәгән илләр, ставкалар югары булу сәбәпле, әҗәтләрен түләү өчен, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсенә чыгымнарын киметә. Боливия, Эфиопия, Тунис һәм тагын башка дистәләгән илнең облигацияләре я дефолт хәлендә, яисә озакламый шул хәлгә киләчәк. Җир шарының төп финансчыларының берсе ясаган нәтиҗә шундый. Дөресен генә әйткәндә, зур державаларның үзләренең финанс хәле дә өченче дөнья илләренекеннән уңай якка әллә ни аерылмый. Хәерче илләрнең дефолтлар парады башланса, турбулентлык бар дөньяның финанс системасын биләп алачак.

Әлегә кабалага баткан илләр үз халыкларының яшәү согын сыккан хәлдә финанс акулаларының иминлеген тәэмин итәргә тырыша. Яңа гына популист Милейны үзенә Президент итеп сайлаган Аргентина халкы шок кичерә: икътисад рецессия хәлендә, болай да чүпкә әйләнеп барган милли валюта – песо берьюлы 54 процентка очсызланды, ягулыкка һәм транспортка субсидияләр киметелде. Милей протест хәрәкәтен тоталь рәвештә бастырырга әмер бирде: кораллы көчләр илдәге забастовкаларны туктатырга, протест белдерүчеләрне кулга алырга тиеш.

Икътисадый яктан нык үскән җәмгыятьләр исемлегенә кергән илләрдә дә хәлләр шәптән түгел. Бөекбритания икътисады октябрь аенда көтелгәннән күбрәк кысылды. Июль аеннан соң икътисадның барлык тармаклары да берьюлы кими. Эчке тулай продукт 0,3 процентка азайды. Германия икътисады – түбәнәю лидерларыннан берсе. Кытай икътисадындагы вазгыять турында әйтеп тормыйбыз, чөнки ул темага күләмлерәк язма әзерлибез.

Дөнья илләренең төп ставкалары исә түбәндәгечә. Ике дистә елдан артык кризистан чыга алмаучы японнар процент ставкасын һаман да тискәре итеп тоталар, чөнки аңлыйлар: ставканы күтәрү япон икътисадын җирләячәк. Аларда төп ставка – минус 0,1 процент. Кытай банкы кредитны 3,45 процент белән бирә. Еврозонада ул 4 процентка тигез. АКШта – 5,38. Аргентина ставкасы – иң югарысы, ул 133 процентны тәшкил итә. Төркия – 40 процент төп ставка белән икенче урында. Алардан соң 16 процент төп ставка белән Россия килә.

Процент капиталы икътисадны үстерүгә хезмәт итми, билгеле. Ул массаларның бөлгенлегенә һәм дәүләтләр арасындагы кораллы конфликтларга китерә. Бүгенге дөньяда без боларның икесен дә күзәтәбез.

Россиядә

РОССИЯ: БЕР ОЧКЫЧТАН АЛЫП МЕҢ ОЧКЫЧКА КАДӘР

Россиянең икътисадый хәлен ТАССның соңгы хәбәрләренең берсе белән сурәтлик: Россия Хөкүмәте каты бодайны экспортлауны вакытлыча тыйды. Йомыркаларны ашыгыч рәвештә Төркиядән ала башладык һәм якындагы көннәрдә аларга бәя төшәр дип өметләнәбез. Хөкүмәтнең азык-төлек инфляциясен авызлыкларга тырышуы күз алдында. Үзәк банкның төп ставканы күтәрүе дә девальвацияне авызлыклау өчен.

Хәер, бәяләр күтәрелү, Путин теле белән әйтсәк, халыкның мул тормышта яши башлавын дәлилли. Һәр нәрсәдә бары тик уңай як кына күрә белү ул – шәп кешеләр эше. Шуңа күрә Путинның халык белән соңгы әңгәмәсе вакытында зәңгәр экранда чыккан «Ни өчен сезнең реальлек безнең чынбарлыктан аерыла?» дигән сорау – вазгыятькә ике төрле караш нәтиҗәсе ул. Пессимистлар, кул кушырып, кара уйга батып утырганда, оптимистлар зур максатлар куя. Һәм вазгыять турында да гел яхшысын гына уйлый. Мәсәлән, «АвтоВАЗ» башлыгы Максим Соколов: «Россия автомобильләре кытайныкы белән көндәшлек итә алмаячак», – дип зарлана һәм автопромга дәүләт ярдәме кирәк дигән якка басым ясый. Чынлап та, Кытай автомобильләре кирәгеннән артык сатып алынган, аларны сакларга хәзер урыннар җитми. Росстат, кытайлар белән сәүдә әйләнеше кызу темплар белән үсә, дигән шатлыклы саннар ирештерә. Моның кайсы яхшырак? Соңгысы, әлбәттә. Кытай иңен куймаса, без бөтенләй кыен хәлдә калыр идек. Кибетләрдә шар тәгәрәтерлек булыр иде. Ә болай кредитка һәм бик кыйбатка булса да, аннан автомобильләр китертеп була.

Путинның 2030 елга кадәр 1000нән артык самолет җитештерергә биргән вәгъдәсен дә төрле кеше төрлечә кабул итә. Бер яктан карасаң, сан фантастик инде, чөнки, әйтик, быел өч Ту-214 очкычы җитештерелергә планлаштырылган, шуның берсе генә сафка басты. Әмма алдагы елларда да хәл шулай булыр дигән сүз түгел. Тулысынча импортны алыштыра торган МС-21 самолеты да ниятләгән санда җитештерелмәде. Әмма 2024 елда – 6, 2025тә – 12, 2026да – 22, аннан соң ел саен 36 самолет җитештерелү планлаштырыла. Саннарга карап, 2030 елга, меңгә үк тулмаса да, үзебезнең 100–200 самолетыбыз булыр дип өметләнә алабыз. Планнар үтәлсә инде.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

ТАТАРГА ТЫЛМАЧ КИРӘКМИ

tatarstan.ru

Үрнәк бюджет, «кирәк була калса» ярдәм итүчеләр һәм татар теле. Хөкүмәт йортында Татарстан Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Салым федераль хезмәте һәм казначылык идарәләренең уртак коллегиясендә әнә шул хакта сөйләштеләр.

Утырышта 2023 елда Татарстан Республикасы тупланма бюджетының үтәлеше йомгаклары һәм 2024 елга бурычлар турында фикер алыштылар. Аны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үткәрде. Йомгаклау чарасында Россия финанс министры Антон Силуанов та катнашты.

Татарстан финанс министры Радик Гайзатуллин узып баручы ел бюджетына бәйле төп саннарны китерде.

– Гомумән алганда, 561,2 миллиард сумлык керемнәр көтелсә, салым һәм салым булмаган керемнәр 476 миллиард сум тәшкил итәчәк. Шуннан республика бюджетына 404 миллиард сум керәчәк. Җирле бюджетларга керемнәр 72 миллиард сум тәшкил итәчәк, – диде ул.

Берләштерелгән бюджетта табышка салым, физик затларның кеременә салым, акцизлар, оешмаларның мөлкәтенә салым саллы өлеш алып тора. «Алар барысы бергә бюджет керемнәренең 84 процентын тәшкил итә», – диде Радик Гайзатуллин.

Чыгымнарга килгәндә, берләштерелгән бюджетта әлеге күрсәткеч – 602 миллиард сум. Республика бюджеты чыгымнары исә 525 миллиард сум тәшкил итә.

– Ел башында калган бюджет акчалары, казна керемнәре хезмәт хакларын үз вакытында һәм тулысынча түләргә, барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларның чыгымнарын финансларга мөмкинлек бирде, – диде Радик Гайзатуллин.

Бу хакта сөйләгәндә, Антон Силуанов министрдан: «Киләсе елда ул-бу була калса, республикада запас бармы?» – дип тә сорады.

Рөстәм Миңнеханов ике дә уйламыйча: «Кирәк була калса, безнең ярдәм сорарга Россия Финанс министрлыгы бар», – дип җавап бирде.

Әнә шулай Мәскәү кунагын үз итеп, Татарстанга күрсәтелгән ярдәм өчен рәхмәт сүзләрен җиткерде ул. Республика башлыгы фикеренчә, киләсе ел бюджеты өчен борчылырга җирлек юк.

Рөстәм Миңнеханов 2023 ел йомгаклары буенча көтелгән төп икътисадый күрсәткечләрне дә атады:

> Агымдагы катлаулы шартларда без икътисадый күрсәткечләрнең үсешен тәэмин итә алдык. Мәсәлән, алдан исәпләүләр буенча, тулаем төбәк продукты күләме 4 триллион сум тәшкил итәчәк. Төяп җибәрелгән продукция күләме 4,5 триллион сум күләмендә көтелә. Төзелеш эшләре күләме 700 миллиард сум тәшкил итә. Иң мөһиме – төп капиталга инвестицияләр күләме 1 триллион сум күләмендә бәяләнә.

Татарстан Рәисе әйтүенчә, әлеге күрсәткечләргә хәзерге кебек катлаулы чорда бизнеска ярдәм итү өчен федераль дәрәҗәдә кабул ителгән карарлар ярдәмендә ирешелде. «Без Россия Президенты Владимир Путинга һәм ил Хөкүмәтенә рәхмәтле», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Антон Силуанов әйтүенчә, Татарстан икътисад өлкәсендә дә, финанс күзлектән дә ил күләмендә әйдәп баручылар рәтендә.

– Республика социаль-икътисадый үсеш рейтингында, Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан кала, өченче урында. Инвестицияләр өчен шартлар тудыруда сез, Мәскәүдән соң, икенче урында. Ил башкаласын гына уздырып, икенче урында булу – бик җитди вазгыять, – диде Антон Силуанов. – Болар барысы да төбәктә инвестицион мохит формалаштыруга, бизнес өчен шартлар булдыруга зур игътибар бирелүен күрсәтә.

Фикерен дәвам иттереп: «Россия Президенты Владимир Путин үзенең матбугат конференциясендә Рөстәм Миңнехановны ил төбәкләре җитәкчеләре арасында иң нәтиҗәле һәм иң яхшылардан берсе булуы турында юкка гына әйтмәде», – дип тә өстәде. Ул республика бюджетын да мактап телгә алды.

– Татарстан бюджеты – ил күләмендә иң яхшылардан берсе. Төбәктә барысы да тотрыклы һәм уңышлы. Без бюджет өчен рәхмәт сүзләре генә әйтәбез, – диде ул.

Үрнәк эшне киләсе елда да дәвам иттерергә кирәк, диде ул.

– 2024 ел – илкүләм проектлар тәмамлану елы. Һәм ил Президенты бездән куелган бурычларның ничек тормышка ашырылуын сораячак. Федерациядән дә, төбәкләрдән дә белешәчәк. Шуңа күрә киләсе елда безгә илкүләм проектларның максатчан күрсәткечләрен үтәү турында онытмаска кирәк. Тагын бер мәсьәлә – без технологик суверенитетны тәэмин итү буенча күп кенә бурычларны тормышка ашырабыз. Республикада да моңа зур игътибар бирелә. Бу хакта сөйләгәндә, оборона-сәнәгать комплексын яңарту турында да әйтү зарур, ул махсус хәрби операция бурычларын тәэмин итү өчен мөһим. Болар барысы да Татарстанда эшли, республика үсештә, – диде министр.

Киләсе очрашуларга тагын бер максат билгеләде Антон Силуанов. Казанга йомгаклау коллегиясенә инде ун еллап ел саен килүен һәм биредә катнашучыларның татарча чыгыш ясавын әйтеп: «Тиздән мин дә татар телендә сөйләшә башлаячакмын», – диде.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

Татарстанның БДБ илләре белән хезмәттәшлеге үзара хөрмәт һәм дуслыкка корылган. Дуслык нык булгач, күрсәткечләр дә яхшы. Аларны Мәскәүдә яңгыраттылар.

Искәртеп үтик: Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустин чакыруы буенча БДБ илләре хакимият башлыклары ВДНХдагы «Россия» күргәзмәсендә катнаша. Сайлап алынган төбәкләр арасында Татарстан да бар.

Күргәзмәдә тәкъдим ителгән Татарстан стендын Азәрбайҗан, Белоруссия, Казахстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Үзбәкстан Премьер-министрлары, Төрекмәнстан һәм Әрмәнстан вице-премьерлары да карады.

Сүз уңаеннан, Татарстан һәм БДБ илләре арасында тышкы сәүдә әйләнеше 15 процентка үскән һәм 2,5 млрд долларга җиткән. 2023 ел нәтиҗәләре буенча Татарстанның тулай төбәк продукты якынча 4 триллион сум тәшкил итәчәк. Төп капиталга инвестицияләр – 1 триллион сум.

Рөстәм Миңнеханов БДБ илләре хөкүмәт башлыкларына хезмәттәшлек турында сөйләде һәм бу мәсьәләләргә шәхси игътибар биргән җитәкчелеккә рәхмәт әйтте.

– БДБ илләре – безнең төп тышкы икътисадый партнерларыбыз, – диде республика җитәкчесе.

Табигатькә зарар китерми, сәнәгый мөмкинлекләре зур. Түбән Каманың «Нижнекамскнефтехим» базасында галобутилкаучук җитештерү буенча яңа производство ачылды. Хәер-фатиханы Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та бирде.

– Бүген бик әһәмиятле вакыйга. 50 ел элек бу урында беренче бутилкаучук җитештерә башлаганнар иде. Ул вакытта елына 35 мең тонна җитештерелгән. Хәзер исә без галобутилкаучук җитештерү буенча яңа сәнәгать производствосы ачабыз, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Бу – бик заманча проект. Ул экология таләпләренә дә җавап бирә, яңа системалар урнаштырылган. Инвестиция күләме – 8 млрд сум. Санкцияләргә карамастан, сез максатыгызга ирештегез. Хәзер продукцияне сатып алучылар базарын киңәйтү, аны алга сөрү эше генә калды.

Төзелеш эшләре барышында 6 яңа сәнәгый җайланма төзелгән, 16сы заманчалаштырылган. Проектны чынга ашыру ил базарын тулысынча галобутилкаучук белән тәэмин итәчәк. Кытай, Һиндстан, Вьетнам, Таиланд кебек илләргә экспорт та каралган.

Галобутилкаучукны, беренчедән, шин җитештерүдә кулланалар. Мондый каучук бәрабәренә шин ныклыгы арта, ул тиз таушалмый, экологик яктан да сыйфатлы. Галобутилкаучукны шулай ук медицина өлкәсендә дә файдаланалар.

АЛА БЕЛСӘҢ, ТОТА ДА БЕЛ

Дәүләт Советында

Узып баручы ел бюджетының керемнәре һәм чыгымнары билгеле. Татарстан депутатлары республиканың төп финанс документына соңгы үзгәрешләрне кертте. Парламент җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин исә финиш сызыгы һәм йомырка бәясе турында да искә төшерде.

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының быелгы соңгы – илленче утырышы узды. Көн тәртибендә утыздан артык мәсьәлә каралды. Исемлекнең бу кадәр озын булуы да аңлашыла кебек, депутатлар бу елга билгеләнгән эшләрне мөмкин кадәр йомгаклады. Утырышта Татарстан Республикасының 2023 ел һәм 2024–2025 еллар план чорына бюджеты турындагы республика законына үзгәрешләр кертү турындагы закон проекты беренче укылышта һәм тулысынча кабул ителде. Шулай итеп, быел Татарстан бюджетының кытлыгы 40,1 миллиард сум тәшкил итәчәк. 2023 елда республика казнасының керем өлеше – 484,7 миллиард сум, чыгымнар 524,8 миллиард сум күләмендә расланды.

– Гомумән алганда, Татарстан бюджетының керем өлеше – 57,8 миллиард сумга, чыгым өлеше 68,2 миллиард сумга артачак, – диде утырышта катнашкан Татарстан финанс министры Радик Гайзатуллин.

Бюджет турында сөйләшкәндә, Фәрит Мөхәммәтшин Россия финанс министры Антон Силуановның республика бюджетын мактавын да искә төшерде.

– Димәк, Татарстан икътисады санкцияләр ил төбәкләре казналарын, шул исәптән республика бюджетын тулыландыруга тискәре тәэсир иткән катлаулы чорны узды, дип ышандырып әйтергә мөмкин. Бу эштә республика хакимиятенең өлеше зур, – диде ул. – Татарстанга теләктәшлек күрсәткән федераль үзәккә рәхмәт. Без акчаны сорап алу гына түгел, ә аны уңышлы һәм максатчан итеп файдалана да беләбез.

Киләсе елда балаларның сәламәтлегенә игътибар да артачак. Депутатлар балалар арасында тәмәке һәм никотинлы продукция куллануга каршы закон проектын хуплады. Документ балигъ булмаганнарны кальян, тәмәке тарту һәм никотинлы продукция куллану рөхсәт ителгән учреждениеләргә кертүне тыя. Шунысын да әйтик: бу – Татарстанга билгеләнгән яңа прокурор Альберт Суяргулов тәкъдим иткән закон проекты.

Казанның чикләре дә киңәйде. Утырышта әнә шул хактагы закон проектын кабул иттеләр. Республика башкаласына «Курган» зират комплексы, «Динамо» спорт-биатлон комплексы һәм «Фәнни шәһәрчек» өстәләчәк. Казан башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Денис Калинкин сүзләренә караганда, башкалага кушылачак объектлар чынлыкта шәһәр территориясе булып санала инде. Шуңа күрә өстәмә чыгымнар таләп ителми, диде ул. Гомумән алганда, Казанда яшәүчеләр саны 600 кешегә артачак.

– Бу ел вакыйгаларга бик бай булды, – диде Фәрит Мөхәммәтшин Дәүләт Советының 2023 елдагы эшенә йомгак ясаганда. – Санкцияләр, махсус хәрби операция шартларында эшләү бер дә җиңел булмады. Әмма без кыенлыкларны җиңеп чыга алдык.

Парламент җитәкчесе алтынчы чакырылыш Дәүләт Советы депутатларының вәкаләтләре ахырына якынлашуын да искәртте. «Финиш сызыгына чыгабыз», – диде ул. Шуңа күрә киләсе елда да эшне йомшартмаска, киләсе сайлауларга әзерләнә башларга киңәш итте.

Дәүләт Советында авыл территорияләрен комплекслы үстерү турында да сөйләштеләр. Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров сүзләренә караганда, Татарстанда соңгы дүрт елда авыл ипотекасы буенча банкларда 37 миллиард сумлык 21 меңгә якын гариза теркәлгән. Шулар арасыннан 12,3 миллиард сумлык 4,9 мең гаризаны хуплаганнар. «Банк кире боруга килгәндә, бу – шәхси мәгълүмат дөрес күрсәтелмәү, керемнәр тиешле күләмдә булмау, беренчел кертем өчен акча җитмәү кебек сәбәпләргә бәйле», – диде министр.

Форсаттан файдаланып, Марат Җәббаровтан республикада йомырка бәяләре турында да сорадылар. «Татарстанда моңа бәйле ыгы-зыгы юк», – диде ул. Рәсми мәгълүматларга караганда, быелның 11 аенда республикада 1 миллиард 453 миллион данә йомырка җитештерелгән. Алдагы елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, бу 33,6 миллион данәгә күбрәк. Марат Җәббаров әйтүенчә, әлеге мәсьәлә федераль дәрәҗәдә дә контрольдә тора. «Шуңа күрә вазгыять якын арада җайга салыначак дип уйлыйм», – диде министр. Фәрит Мөхәммәтшин йомырка бәясен даими күзәтеп торырга кушты.

Эльвира ВӘЛИЕВА

2023 елда Татарстан Дәүләт Советының эше – саннарда:

- Парламентта **12** утырыш узган.
- Аларда **400** карар кабул ителгән.
- **60**тан артык федераль закон проекты, **10**нан артык закон чыгару тәкъдиме һәм ил төбәкләре мөрәҗәгатьләре каралган.
- Дәүләт Советы тарафыннан **125** Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «Теләкләр чыршысы» хәйрия акциясенә кушылды. Парламент җитәкчесе Ясминә һәм Айсельнең хыялларын чынга ашырачак. Казанда яшәүче 3,5 яшьлек Ясминә алсу төстәге велосипед сорап хат язган. Сирәк очрый торган авыру белән чирләсә дә, яшьтәшләреннән калышырга теләми ул. Ясминәнең велосипедта йөрергә өйрәнәсе килә. Айсель дә, сәламәтлеге чикләнгән булуга карамастан, тик утыра торганнардан түгел. Баксаң, ул конструктор җыярга ярата икән. Фәрит Мөхәммәтшин аңа зур җыелма конструктор бүләк итәргә вәгъдә бирде. Акциягә Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин да кушылды. Ул Әлмәттә яшәүче 10 яшьлек Билалетдиннең теләген тормышка ашырачак. Малай велосипедлы булырга хыяллана. «Теләкләр чыршысы» акциясе 15 ноябрьдә башланды һәм киләсе елның 28 февраленә кадәр дәвам итәчәк.

ЯРДӘМНЕҢ АРТЫГЫ ЮК

Махсус хәрби операциядә катнашучы хәрбиләргә кыш көне ничек ярдәм итәргә? Бүген аларга нәрсә кирәк? Билгеле бер кешегә ярдәм җибәреп буламы? Бу һәм башка сорауларга җавап бирергә «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» республика хәрәкәте җитәкчесенең урынбасары Анна МӨБАРӘКШИНА ярдәм итте.

:: Билгеле бер батальонга, хәрби частька ярдәм җибәрергә теләүчеләр кемгә һәм кая мөрәҗәгать итә ала?

– Адресны ярдәм буенча мәгълүматны без командирлар белән берлектә туплыйбыз. Алар безгә тегө яисә бу взвод өчен азык-төлек, кием-салым, дарулар, инструментлар, хәрби техника һәм башка кирәк-ярак язылган исемлек җибәрә. Без исә ул исемлекне ярдәм.рф сайтына урнаштырабыз.

Ул исемлек белән танышу өчен, беренчедән, сайттагы «Помочь» төймәсенә басарга, икенчедән, «Принести в пункт сбора» өлешендә «Список необходимых вещей» төймәсен табарга кирәк. Шунда ук һәр шәһәр һәм районнардагы ярдәм кабул итү пунктларының адреслары да бар. Ә инде акчалата ярдәм итәргә теләүчеләр «Поддержать» төймәсенә баса.

Ярдәм итәргә теләүчеләр безнең «кайнар линия»гә дә шалтырата ала. Нәрсә кирәген, кайсы кирәк-яракны кая алып барып тапшырасын хәбәр итәләр.

:: Ә сезнең аша билгеле бер кешегә посылка җибәрү мөмкинлеге бармы?

– Бәрәр кая барабыз икән, үзебез белән тегә яки бу кешегә бирелергә тиешле посылканы да ала алабыз. Әммә без барасы юнәлеш белән ул кеше хезмәт итә торган подразделение туры килергә тиеш.

Сан

Соңгы мәгълүматлар буенча, «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» хәрәкәте хәрбиләргә һәм Луганск Халык Республикасында яшәүчеләргә барлыгы **1194 тонна** ярдәм җибәргән.

«Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» фондының «кайнар линия»се номеры: 8 (800) 350-02-16 (шалтыратулар көн саен 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр кабул ителә).

:: Кышкы сезонда хәрбиләргә ничек ярдәм итәргә? Бәлки, аерым исемлек бардыр?

– Безнең сайттагы исемлек гел янарып тора. Кышка аяк баскач, кубесенчә төзелеш материаллары, дарулар, озак саклана торган азык-төлек һәм җылы киемнәр җибәрәбез. Әйтик, кирәкле азык-төлекне генә алыйк. Ярдәм итәргә теләүчеләр чәй, каһвә, кондитер эшләнмәләре (печенье, конфет), консервалар, тиз пешерелә торган пюре, лапша һәм ашлар тапшыра ала.

:: Гуманитар ярдәмне еш җибәрәсезме?

– Айга бер мәртәбә. Бер ай дәвамында халыктан килгән ярдәмне җыеп, кирәкле әйберләрне сатып алып, барысын да тәртипкә салабыз, транспорт табабыз һәм җибәрәбез. Гаризалар килеп тора, без әзерләп торабыз. Халык бик актив, ярдәм итүчеләр бик күп, шуныс сөендерә. Районнардан да җыеп китерәләр.

:: Эш белән ярдәм итәргә, ягъни волонтер булырга теләүчеләр күпме?

– Җитәрлек. Безнең волонтерларның күбесе – төрле уку йортлары студентлары. Гомумән, теләгән һәркем волонтер була ала. Моның өчен нәрсә эшләргә кирәклеге шулай ук безнең сайтта аңлатылган.

Моннан тыш, без хәзер волонтерлык оешмалары белән дә эшлибез. Алар, әйтик, маскировка челтәрләре үрә, формалар тегә, квадрокоптерлар ясый. Без гариза бирәбез, алар кирәкле әйберләрне әзерли.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

САБЫЙЛАРГА – КҮЧТӘНӘЧ

«Единая Россия» партиясенең Татарстандагы бүлеге фронтка һәм Луганск Халык Республикасына 19 мәртәбә гуманитар ярдәм җибәрде. Бу юлы йөк тәягән машиналардагы күп урынны балаларга дип әзерләнгән 9,5 мең данә Яңа ел күчтәнәче алып тора иде. Аларны Лисичанск һәм Рубежноеда яшәүче сабыйларга таратачаклар. Моннан тыш, җәмгысы йөз тонналы алты фурага төягән кирәк-ярак арасында төзелеш материаллары, сантехника, медикаментлар, кием-салым, көнкүреш химиясе һәм башкасы бар иде. Ярдәмне бөтен Татарстан: республика районнарында яшәүчеләр, депутатлар, бизнесменнар җыйган.

«ЯРДӘМ ЯНӘШӘ! ПОМОЩЬ РЯДОМ!» ТАГЫН КЕМНӘРГӘ ҺӘМ НИЧЕК ЯРДӘМ ИТӘ?

➤ Бушлай юридик ярдәм (мобилизация, ташламалар һәм түләүләр билгеләүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен, бушлай консультацияләр уздыралар).

➤ Бушлай психологик ярдәм (хәрбиләрнең гаиләләренә онлайн, индивидуаль һәм төркем сессияләрендә психологик ярдәм. Психологлар районнарга да чыга). «Кайнар линия» телефоны: **8 (800) 250-18-59.**

Ватан хакына

ИРЕ ЯНЫНА ФРОНТКА БАРЫП КАЙТКАН АЙГӨЛ:

«ОЧРАШУГА ИКЕ АЙ ӘЗЕРЛӘНДЕМ»

Яратсаң, барысын да эшлисең! Буада яшәүче Айгөл Афанасьева әнә шулай ди. Ул махсус хәрби операциядәге ире янына барып кайткан. Андагы хәлләрне үз күзем белән күрәсем килгән иде, ди ул.

– Өлешчә мобилизация башлануга, иремә повестка килде. Ике балабыз бар. Бер дә җибәрәсем килмәсә дә, язмышыбыз белән килештем. Ватанны кем саклар, дидем. Башта ирем бер айга якын Казанда торды. Аның янына атна саен барып йөрдем. Киткәч тә, хәбәрләшеп тордык. Шалтыратуын өзелеп көтә идем, – дип искә ала Айгөл.

Айраты 7 айдан соң ялга кайта. Бик бәхетле ике атна вакыт тиз узып китә. Быелның сентябрендә икенче тапкыр ялга кайта ул.

– Аерылышу бик авыр булды. Каядыр эшкә китсә, әле башкача кабул итәр идең. Махсус хәрби операциядә булгач, күңел тынычлана алмый. Бер ел эчендә ул да, без дә үзгәрдек. Төрле чаклар була. Елыйм да инде, әммә бирешмәскә тырышам. Балаларның да шуңа өйрәтәм. Алга атлаганда, артка чигенергә ярамый, дим. Башкача максатына ирешеп булмаячак, – ди Айгөл. – Инде ир-ат эшләренә дә өйрәндем. Ватылганны төзәтәм, җимерелгәнне рәтләп куям. Ирсез яшәүнең никадәр кыен икәнен аңладым. Күңел дә тыныч түгел. Ирем элемтәгә чыкмаса, утта янам. Әле ярый ирләребезнең хәлен белеп торырга махсус төркемебез бар.

Анда 35 кеше икән. Махсус хәрби операциядә бергә булган егетләрнең хатыннары, әниләре шунда язышa. «Бер ел эчендә иң якын кешеләргә әйләндек», – ди Айгөл. Бар борчулары шунда аларның. Яшерми, югалтулар да бар. Андый чакта бер-берсенә терәк булырга ашыгалар. Әгәр берсе ире янына юлга кузгала икән, калганнар күчтәнәч җибәрә.

– Минем бик тә иремне барып күрәсем килде. Бу хакта ике ай хыялландым. Дөресрәге, ике ай буе кая гына язмадым, кем белән генә элемтәгә кермәдем. Башта автобуска китәсе идем. Аннан поездда бармакчы булдым. Соңыннан бер егетнең әнисе, машина белән барам, бездә урын бар, дип язды. Бик теләп аларга иярдем. Ирем алгы сызыкта булса да, командирлары белән сөйләштем. Шөкер, аңладылар. Бер тәүлек булса да, ирем белән бергә булдым. Мин килеп җиткәч, иремнең күзләрен күрсәгез иде. Шулкадәр балкыды алар. Бакчада әнисен көткән сабыймині... Бик озак кочаклашып елашдык, – ди Айгөл. – Күп итеп тәмле ризыклар алып бардым. Тозлаган яшелчәләр, салатлар да тутырдым, камыр да пешердем. Мантый сораган иде, анысын да күп итеп әзерләп алып бардым. Бик яратып ашадылар. Мин алар яшәгән йортларда булдым. Анда – башка тормыш. Аны күргәч, мондагысына мең мәртәбә шөкер итәсең. Андагы басулар буп-буш. Аларга карагач, шомлы булып китә. Окопларда тычканнар күп. Ирем торган йортта да бар алар.

Ул Айраты турында бик яратып сөйли. Матур яшәгәннәр. Бер-берсенә авыр сүз әйтү, рәнҗетү булмаган. Тормышларына сөенеп, кадерле булып гомер иткәннәр.

– Яратуыбыз көчле. Безнең бит бер атнадан артык аерылышып торган юк иде. Әлеге хәлләр безне тагын бер кат сынады. Бер-беребезгә булган хисләр тагын да ныгыды. Ул да сагына, мин дә, балалар да. Инде икенче Яңа елны әтиләреннән башка үткәрәбез. Балалар тизрәк әтиләре кайтуны көтә, – ди Айгөл. – Иремнең акчасының яртысы үзенә китеп бара. Кирәк-ярак алып җибәрәм. Яртысын җыеп куям. Аның хыялы бар, кайткач, шуны тормышка ашырмакчы. Балалар белән үземә акчам җитә. Эшем бар, хезмәт хакы алам, зарланып булмый. Миңа иремнең бер тиене дә кирәкми. Үзе кирәк. Ул монда да начар хезмәт хакы алмады. Яныбызда булуын бернидән сумнар алыштырмый. Бер генә теләгебез: исән-имин яныбызга кайтса иде. Гомумән, һәркемнең газизе өенә исән-имин әйләнеп кайтсын!

Сүз уңаеннан, иренең командиры Буа районы хакимияте җитәкчелегенә Рәхмәт хаты да биреп җибәрә. Анда мондый сүзләр бар: «Ефрейтор Айрат Афанасьев һәм сержант Александр Буркин хәрби бурычларын лаеклы үти, хезмәттәшләре өчен хәрби осталыкны арттыруда үрнәк һәм Ватанны ышанычлы саклыйлар».

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Ярдәм янәшә!

Игътибар үзәгендә

Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның балаларына бакчаларда, мәктәпләрдә, югары уку йортларында, көллият, техникумнарда нинди өстенлекләр каралган? Шул хакта искә төшерәбез.

Югары уку йортлары. «Россия Федерациясендә Мәгариф турында» законга үзгәрешләр кертергә җыеналар. Тәгаенләп әйткәк, бу үзгәреш махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның балаларына, көллият-техникумнарга укырга керү өчен, квота бирүне күздә тота.

Вузлар мондый мөмкинлекне бирә инде. Татарстанның вице-премьеры Ләйлә Фазлыева әйтүенчә, Татарстанда мондый квота буенча ике йөзләп кеше укырга кергән.

Моннан тыш хәрбиләр һәм аларның балалары түләүле уку бүлегеннән бюджет урыннарына күчү хокукына ия. Билгеле, вузның буш урыннары булса һәм студентның уку буенча бурычлары булмаса.

Бюджет урыны җитәрлек, шуңа да махсус квоталы абитуриент бөтен кешенең өлешенә керә дигән уй булырга тиеш түгел. Казан федераль университетының тышкы элемтәләр буенча проректоры Тимерхан Алишев әйтүенчә, югары уку йортларына кабул итү кысасында бюджет урыннарының (төрле юнәлешләр буенча) гомуми санының 10 проценты квота өчен билгеләнеп куелган. «Ягъни әлеге урыннар махсус хәрби операциядә катнашучыларның балалары өчен. Быел махсус квота буенча безнең ике хәрби һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның 47 баласы укырга керде», – дип аңлатты проректор.

Билгеле, абитуриентның имтихан балларына да игътибар итәләр. Ул минимумны җыйган булырга тиеш.

– Әгәр дә квота буенча бюджет урыннары җитмәсә, вуз студентка йөз процент ташлама бирә. Безнең университетта шундый җиде студент укый иде. Ягъни алар контракт нигезендә укыйлар, әммә вуз, бюджеттан тыш акча исәбенә, аларның укуы өчен түли», – диде Тимерхан Алишев.

Балалар бакчасы һәм мәктәп. Ләйлә Фазлыева искәрткәнчә, мәктәпләрдә белем алучы балалар ике тапкыр бушлай туклана. Моннан тыш балалар иҗади түгәрәкләргә, секция, озайтылган көн төркеменә дә бушлай йөри. «Мондый мөмкинлектән 6 меңләп бала файдалана», – диде Ләйлә Фазлыева.

Шунысын да искәртергә кирәк: махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләре балалар бакчасына түләүдән азат ителгән. Республикада 4 меңләп бала шушы ташламадан файдалана. 416 бала балалар бакчаларына урнашканда өстенлекле хокуктан файдаланган.

Яңа ел чыршысы. Республиканың төп Яңа ел бәйрәмене 17 мең мәктәп укучысы чакырылы. Шуларның 9 меңнән артыгы – махсус хәрби операциядә катнашучыларның балалары (7–17 яшькәчә балалар). Бәләкәчләр өчен Яңа ел бәйрәме район җирлекләрендә оештырылачак.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Фикер

Ләйлә ФАЗЛЫЕВА, Татарстанның вице-премьеры:

– Мәктәп укучыларының хәрбиләргә атап язган хатлары күңелгә бик тия. Мондый хатларны алган хәрбиләр дә бу хакта бик җылы итеп сөйли. Хатлар турында сораша башласак, хәрбиләр аның һәр сүзен әйтеп бирә ала. Мондый акцияләрдә катнашкан кешеләргә рәхмәт әйтәсе килә!

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНУ, ДӘВАЛАНУ ҺӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ ҺӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ ҺӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР ҺӘМ ГАРАНТИЯЛӘР



ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Тарих – ялгышлар җыелмасымы?

Тарихны мәктәптә укыганда ук нык ярата идем. Тик, ни кызганыч, язмыш мине гуманитарий итмәде. Гомер буе җитештерүдә, кем әйтмешли, тимер-томыр арасында кайнап, тарихка мөкиббән калу, аны күпмедер дәрәҗәдә белү, аңлау авыр шул. Шулай да ике дистә еллар чамасы элек күңелдә нидер кузгалды: тулаем гуманитарлыкка кереп китмәсәм дә, тарихка булган мәхәббәт яңарды. Башыннан аягына кадәр технарь булган фәкыйрегез, кайда тарихка кагылышлы нинди мәгълүмат бар, һәммәсен укып, карап, булдыра алганча хәтеренә сеңдереп бара башлады. Әлбәттә, андый очракта ниндидер системалылык турында сүз була алмый. Диванга утырып өйрәнгән тарих югары уку йортында алган гыйлем түгел шул. Ләкин дәртле кызыксыну ул юнәлештә нидер аңларга, хәтта белергә ярдәм итми калмады дисәм, алдашмам кебек.

Гуманитар фәннәрнең, шул исәптән тарихның да, техник фәннәрдән бер өстенлеге бар: алар мәңгелек кыйммәтләргә якынрак тора. Шул ук техника, электроника бүген бертөрле булса, ике-өч дистә ел узуга ул инде үзгәргән – башка төрле. Электровоз булганда кем генә вагоннарны паровозга тагар икән? Ә кешелек үткән юлны өйрәнгән, күпмедер белгән, аның белән даими кызыксынган очракта, тирә-як чынбарлыкны гына түгел, хәтта үзеңне дә яхшырак аңлыйсың кебек. Аерым кешенең нәрсәнедер яхшырак аңлавыннан җәмгыятькә файда күп булмаса да. Кайчакта тарихны барлык уку йортларында да төп фән итәсе иде, дигән уйлар да килә.

Чөнки кешелекнең олы фаҗигасе шунда: тарих безне бернәрсәгә дә өйрәтми, без аннан сабак алып яши белмибез. Яшәгән саен бер үк тырмага китерәбез дә басабыз, китерәбез дә басабыз. Маңгаебызда тырма сабы эләкмәгән урын инде калмады да бугай. Тарихыбызның, зурдан алганда, сугышлар тарихы булуы моңа иң үтемле дәлил түгелме? Гади халыктагы тарихи белем шундый: ул Бөек Ватан сугышы башланган, беткән еллардан, Октябрь инкыйлабы яралган датадан артыкны белми, белүне кирәк тә санамый. Вакыйгалар, алардагы сәбәп – нәтиҗә бәйләнешләре аның өчен гомумән дә ят нәрсә. Халык арасыннан чыккан, без җитдигә, җаваплыга, белемлегә санаган дәүләт җитәкчеләре дә, чынлыкта, тарихтан сабак алып, гамәл кылырга күнекмәгән.

Ә бит тарих дигәнебез – кешелекнең күмәк хәтере булырга тиешле фән. Ялгышлар җыелмасы түгел. Хәтер, бер яктан караганда, бар да кебек: тарихи елъязмалар, архивлар, тарих институтлары, галимнәр, фәнни хезмәтләр, дәреслекләр. Менә шулар барысы бергә бездә киләчәк алдында җаваплылык тәрбиялиме, тарихи тәрбия бирәме, дигән сорау туа. Юк, тарих һаман да тар даирә белгән өлкә булып кала. Халыкта да, шул ук сәясәтчеләр, югары түрәләрдә дә тарихи гыйлем булырга тиешлеге минем өчен бәхәссез. Сәясәтчеләрнең һәммәсеннән дә, хакимияткә килгәнче, хәлемнән килсә, ким дигәндә кандидатлык минимумы тапшырттырыр идем. Югары вазыйфадагы затлар алда искәртелгән сәбәп – нәтиҗә бәйләнешләрендә судагы балык кебек йөзәргә тиеш түгелме икән: кайсы дәвердә нинди гамәлләр нинди аяныч нәтиҗәләргә китергән, кем кайчан төзәлмәс хата ясаган...

Бүгенге дөньяга, анда барган вакыйгаларга карап: «Тарихи тәрбия һәм тарихи хәтер акыл җитмәү сәбәпле җитенкерәми», – дигән өметсез нәтиҗәгә килеп була кебек. Нәкъ менә сай акыллылык. Югыйсә тарих күрә, ишетә, укый, өйрәнә белгәннәргә үткән дәверләрдә күпме ялгышлар кылынганын, нәрсә хакына, ни өчен кан елгалары акканын, ни сәбәпле дәүләтләр нигезенә чаклы җимерелгәнен бәйнә-бәйнә сөйләп тора бит. Ә адәми зат, ничә тапкыр кыйналып та, яңадан кәбестә бакчасына кергән кәҗә кебек, үткәннең хаталарын даими кабатлый. Кайда монда акыл?

Акылсызлык, хәтерсезлек, сансызлык. Дәүләт дигән берләшмәләр, диннәр яралу бер яктан уңай күренеш саналса да, икенче яктан ул халыкларның бер-беренә булган мөнәсәбәтен кискенләштергән. Дин идеология чыганагы булган кебек, дәүләтләр дә аннан баш тартмый. Ә идеология, башкача әйткәндә – котырту, кемдер уйлап чыгарганны массаларга сеңдерү, аларны теге яки бу тәгълимат белән исертү ул. XX гасырдан башлап дингә катнашы булмаган идеологияләр (нацизм, коммунизм) яралып, нәкъ шулар глобаль фаҗигаләргә юл ачты. Кеше затына, тыныч яшим дигәндә, идеологиядән дә, пропагандадан да тулаем баш тартасы. Дәүләтләр бәндәне нәрсәгәдер инандыру һәм котыртудан туктамыйча, тарих безне бернәрсәгә дә өйрәтмәячәк.

Пропагандистлар, мәсәлән, бик теләп «данлы үткәннәр» ише идеологик клише, калыплар кулланырга хирыс. Тик менә кайсы дәүләт тарихына гына карама, мактанырлык вакыйгалар аз, гыйбрәт алырдайлар күп. Наполеон җиңүләре шул ук французлар өчен данлы үткәннәрме әллә? Һич юк. Ымсындыргыч «якты киләчәк» сүзе белән дә шул ук хәл. Яңгыравык шигарьләр, матур киләчәк хакына бирелгән корбаннарның бер илгә дә затлы иртәгәне алып килгәне юк әле. Үткәннәрне артык данламыйча, халыкны якты киләчәк белән алдамыйча, тарихтан сабак алып, бүген белән яшәү дөресрәк түгел микән? Без бит менә бүген, хәзер яшибез. Нәкъ шул бүгенгебез матур да, күркәм дә булырга тиеш. Бер үк вакытта бүгенге көн – үткәннең нәтиҗәсе. Үткәнне матурлап күчереп язып кына бүгенге көнне яхшыртып булмый.

«Үткән белән идарә иткән киләчәк белән дә идарә итә. Бүгенге белән идарә иткән үткәнне үзгәртә». Халыкны миңгерәүлектә тотучы йомык әйләнәне аңлаткан бу формуланың кайсы әсәрдән икәнен укучы чамалагандыр. Бу – данлыклы «1984» романы авторы Джордж Оруэллның киләчәк буыннарны үзенчә кисәтүе, шундый көнгә калмагыз, уяу булыгыз, хәтерле булыгыз, дию...

АННАН (КЕМНӘН) ҮРНӘК АЛАСЫ

МӘДӘНИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ СОВЕТЫ УТЫРЫШЫНДА ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕЛӘР

Ни өчен бездә һаман заман герое юк? Яшьләр кемнән үрнәк алырга тиеш? Алар Ватанны яратсын өчен нәрсә эшләргә кирәк? Татарстан Рәисе каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советы утырышында бу сорауларга янә бер кат җавап табарга тырыштылар. Нинди нәтиҗәгә килделәрме? Җавабы – безнең язмада.

«Татар-информ»

Театр яктылыкка...

Бүген яшьләр сокланырдай заман геройлары юк. Татарстан Рәисе катнашында узган әлеге чарада мәдәният министры Ирада Әюпова әнә шулай диде. Патриотизм турында сөйләгән чакта, яшьләр күбесенчә совет заманында популяр булган образларга таяна, чөнки бүген таянырдай образлар юк. «Аларны хәзер, әйтик, заманча сериаллардагы «ясалма» геройлар алыштыра. Яшьләребезне югалтмас өчен, мәдәният оешмаларының репертуарга кагылышлы сәясәтен яңартырга, барларга кирәк», – диде министр.

Шуннан соң ул Татарстан театрларының репертуарына күзәтү ясады, патриотик рухтагы спектакльләрне арттырырга кирәклеген әйтте. Тик телгә алынган кино сәнгатен театр белән бер үлчәүгә салу ни дәрәҗәдә дөрес икән? Ягъни беренчесенең йогынтысы һәм тамашачысы күбрәк булган заманда, яшьләр өчен кызыклы булырлык, Ватанга мәхәббәт уятырлык сыйфатлы фильм-сериаллар төшерү турында сөйләшергә вакыт җитмәдеме? «Бу начар», – дип төртеп күрсәткән вакытта, «яхшы»ны да тәкъдим итәргә кирәк бит.

Ирада Әюпова махсус хәрби операциядә катнашучыларның якыннарына күрсәтелгән һәм күрсәтеләчәк ярдәм чараларына, музейларда бүгенге геройларга багышланган почмаклар булдыруга, авыл мәдәният йортлары һәм китапханәләрендә һөнәрчелек үзәкләре ачуга да тукталды. Гаилә елына аяк баскач, 1 февральдән «гаилә абонементы» эшли башлаячагын да хәбәр итте. Анысы исә төрле мәдәният оешмаларының бергә уздырачак чараларына гаилә белән бергә барырга мөмкинлек бирәчәк. «Киләсе елда театрларга гаилә кыйммәтләрен пропагандалауга игътибар бирергә кирәк булачак», – диде ул. Һәм уңай мисал буларак Камал театрында бара торган «Ситса туй» спектаклен атады.

> **Кызганыч, соңгы 30 елда без дәүләт идеологиясе турында сөйләшергә курыктык. Әмма Ватан белән бәйләп торучы асылыбызны аңламасак, тамырларыбыз турында уйламасак, киләчәккә атлау авыр булачак, – дип йомгаклады сүзен министр.**

Үзебезгә – үзебез

Заманча драматургия күбрәк булсын, әмма классиканы да сакларга кирәк. Министр башлаган театр темасын «Әкият» курчак театрының сәнгать җитәкчесе Илгиз Зәйниев дәвам итте. Ул берничә тәкъдим белән чыгыш ясады. Беренчедән, татар драматургиясе классикасын күптомлы бер басмага җыярга кирәк. Театрларда һаман бер үк авторлар, һаман бер үк әсәрләр куелмасын өчен дә яхшы чара булыр иде ул. Икенчедән, безгә үзебез өчен режиссерларны үзебезгә әзерли башларга кирәк.

– Татар театры традицияләрен киләчәк буын режиссерларына тапшырасы иде. Моның өчен татар театры каршында, Фәрит Бикчәнтәев җитәкчелегендә махсус курс ясарга тәкъдим итәм, – диде Илгиз Зәйниев.

Бу тәкъдим – яңалык түгел. Шушындый утырышларда да берничә мәртәбә телгә алынган тема. Инде хәзер эшлисе генә калды.

Хагги-Вагги урынына – Барсик

Тәрбия һәм заман геройларына әйләнеп кайтыйк. «Алдынгылар хәрәкәте»нең республика бүлеге җитәкчесе Тимур Сөләймановның да ялкынлы чыгышы шул турыда иде. Аерым алганда, балаларның безнең традицион кыйммәтләргә туры килмәгән геройларга охшарга теләве турында борчылып сөйләде ул. Безнең балаларның әлеге дә баягы Хагги-Вагги уенчыгына, «Скибиди-туалет» ише веб-сериаллардагы геройларга, блогерларга мөкиббән китүен яхшыга илтмәячәген искәртте. Монысын аңлыйбыз, ә нәрсә эшләргә?

– Безгә үзебезнең яңа образларны булдырырга кирәк. Әйтик, Татарстанның милли символы – барс, – диде ул, кулындагы йомшак уенчыкны күрсәтеп. – Барс образы төрле формаларда – спектакльләрдә, мультфильмнарда, уенчыклар рәвешендә булырга тиеш. Олыракларга – «КамАЗ»лы узышлар, үзебезнең комикслар, фильмнар...

> **Сан**
>
> Тимур Сөләйманов сүзләренчә, бүген **10–13** яшьлек балаларның 65 проценты блогерлар карый, **55** проценты киләчәктә блогер булырга тели.

Кыскасы, заман герое, милли герой темасы әле дә актуаль. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов сүзләре белән әйтсәк, булганнарын нигә күрсәтмибездер...

– Алар кем үрнәгендә үсә? Нәрсә карый? Безнең үрнәк итеп күрсәтердәй геройларыбыз күп бит! Махсус хәрби операция геройлары, спортчылар, хезмәт алдынгылары... Ник күрсәтмиләр аларны? Кем икәнлекләре, нинди гамәлләр башкарганнары турында нигә сөйләмиләр? – диде ул.

Иртәгә үк берни дә үзгәрмәячәк. Утырыш әнә шул фикер белән тәгәлләнде.

– Яшь буынга патриотик тәрбия бирү – системалы эш. Ул гаиләдә, балалар бакчасында, мәктәптә алып барылырга тиеш. Моның өчен мохит булдырырга кирәк. Ләкин бүген сөйләштек тә иртәгә нәтиҗәгә ирештек түгел – ни дә булса үзгәртер өчен вакыт кирәк, – диде Татарстан Рәисе.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Яшәргә өйрәнәбез

МӘСКӘҮ – КАЗАН АРАСЫ:

4481 СУМ ТҮЛӘП БАРАСЫ

«Татар-информ»

> ### Кечкенә дә төш кенә
>
> Түләүле юлдан хәрәкәт иткән өчен акчаны дәүләт компаниясе сайты яки махсус кушымта аша түләргә мөмкин. Юлда берниндн шлагбаумнар да очрамаячак. Шуңа күрә тизлекне дә киметәсе юк. Автомобильнең дәүләт номеры махсус кушымтада теркәлгән очракта, юлдагы махсус рамкалар машинаны үзләре танып беләчәк һәм телефон хуҗасына хәбәр салачак. Шунысы да бар: акчаны биш тәүлек эчендә түләргә кирәк. Югыйсә штраф чәпәячәкләр.
>
> – Түләүле юлдан йөрүчеләр арасында транспондердан файдаланучылар артканнан-арта, – ди «Автодор» дәүләт корпорациясенең сату-алулар секторы җитәкчесе Алексей Тимченко. – Бу – үзенә күрә юл билеты. Аны сатып алмыйча, дәүләт оешмасыннан тәүлегенә биш сумнан арендага да алырга була. Транспондер белән түләү отышлырак та әле. Чөнки 5тән 20 процентка кадәр ташлама каралган. Тәүге ташламаны алу өчен, түләүле юлдан 50 чакрым узарга кирәк.

Тиздән ачылачак М12 юлыннан Казаннан Мәскәүгә барып җитү өчен күпме түләргә кирәк икәнен әйттеләр. Россия Президенты Владимир Путин үткәргән «туры элемтә»дә яңа юлның бәясе кыйммәткә төшүдән зарланганнан соң, «Автодор» мәсьәләгә ачыклык кертте. Баксаң, юл хакы Мәскәүгә якынлашкан саен арта.

– М12 югары тизлекле юлын ел азагына кадәр кулланышка тапшыру күздә тотыла. Бүген аның буенча Мәскәүдән Арзамаска кадәр барып җитәргә мөмкин. Түләүле трассаның әлеге өлешендә хәрәкәт итү бәясе 2800 сум тора, – ди «Автодор» дәүләт корпорациясенең идарә рәисе урынбасары Константин Макиев. – Мәскәүдән Казанга беренче борылышка кадәрге араны алсак (Р241 Казан – Буа – Ульяновск автомобиль трассасына борылып төшү чаты. – **Ред.**), җиңел машина йөртүчеләргә юл хакы 4481 сум тәшкил итәчәк.

> Транспондер ул – түләүле юллардан хәрәкәт итүне җиңеләйтүче электрон җайланма. Зурлыгы ягыннан учка да сыя. Машинаның алгы тәрәзәсенә беркетелгән әлеге тартмачык ярдәмендә юл өчен автомат рәвештә исәп-хисап ясарга мөмкин.

Шунысын да искәрткәннәр: Мәскәүдән Казанга юлны дәвам иттереп, Идел елгасы аша чыккан өчен, өстәп 319 сум түлисе булачак. Яңа юлны күбрәк таптаган саен очсызрак та әле. Константин Макиев шулай ди.

– Түләүле юлдан еш йөрүчеләр гадәттә исәп-хисап ясау өчен махсус җайланма – транспондердан файдалана. Аның буенча өстәмә ташлама да каралган. Ягъни түләнгән һәр 50 чакрым юл өчен балл исәпләнә, аны алга таба ташлама ясау өчен кулланырга мөмкин. Мәсәлән, Казаннан Мәскәүгә ике тапкыр барып кайтсаң, транспондер хуҗаларына киләсе сәфәр 15 процентка арзангарак төшәчәк. Баллар М4, М11 кебек башка трассаларда хәрәкәт иткән вакытта да туплана. Мәскәүдән Казанга беренче борылышка кадәр юл бәясен чагыштырсак, ташламалы юл хакы 3800 сум торачак.

Билгеле булганча, бу атнада Россия Президенты Владимир Путинга «туры элемтә» барышында М12 югары тизлекле юлыннан йөрү бәясе артык кыйммәт булудан зарландылар. Әйтүләренчә, яңа юлның бер чакрымы уртача 7 сум тора, Мәскәү – Казан арасы исә якынча 6 мең сумга төшәчәк. Ноябрь аенда журналистларга М12 юлын күрсәткәндә (анда «ВТ» хәбәрчесе дә катнашты), «Автодор» вәкилләре ике башкала арасының якынча шулкадәр торачагын фаразлаган иде.

– Миндә булган мәгълүматларга караганда, ике шәһәр арасының бәясе 4–4,5 мең сум торырга тиеш, – диде Владимир Путин. – Минем 6 мең сум турында ишеткәнем юк. Бәлки, юлның һәр өлешендә дә бәяләр бер үк түгелдер. Моны тикшерәчәкмен. Әлеге мәсьәләдә коры арифметика белән генә исәп-хисап ясарга ярамый дип саныйм.

Президентның бер сүзе җитте. Юл хакына шунда ук ачыклык керттеләр. Константин Макиев буталчыкның нәрсәдән килеп чыкканын да әйтте.

– Мәскәү – Арзамас арасы 2800 сум торгач, ә ул гомуми юлның яртысын тәшкил итә, барлык трассаны үтү 6 мең сум чамасына төшәчәк, дип ялгыш фикер йөртәләр, – ди урынбасар. – Арзамастан Казанга кадәр ара, ташламаларны исәпкә алмыйча, 1900 сум торачак. Бу әле – Шәле борылышына кадәр барып җитүчеләр өчен бәя. Казанга беренче борылышка кадәр юл бәясе 1700 сум тирәсе тәшкил итәчәк. Мәскәүгә якынлашкан саен олы юлның һәр чакрымы кыйммәтрәк тора. Ник дисәгез, биредә полосалар саны да күбрәк, юлның машиналар үткәрә алу мөмкинлеге дә зуррак. Түбән Новгородтан Казанга таба юл 20 процентка диярлек арзангарак төшәчәк.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ТЫНГЫСЫЗ РӘМЗИЯ

АВЫЛДА РУСЧА СӨЙЛӘШҮЧЕ БАЛАЛАРНЫ УКЫТУЧЫ ҮЗГӘРТӘ АЛЫРМЫ?

И туган тел!

Әтнә районындагы Күлле Киме мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы Рәмзия Хөсәенованың бу көннәрдә аптырап йөргән чагы. Саф татар авылында туып-үскән укучыларының татарча белмәве өчен борчыла ул. Ипине – «хлеб», атны «конь» ди алар. «Татарча ничек була?» – дигәч, җилкәләрен генә сикертәләр. Шул ук вакытта Иорданиядән кайткан Габдрахман ничек туган телен онытмаган соң?

Рәмзия – 60 хуҗалыклы Бәхтияр авылы кызы. Кияүгә чыккан авылы Бахтачы моннан берничә тапкыр кечкенәрәк. Анда йортлар саны елдан-ел кими бара. Кыш көне тугыз йортта 19 кеше яши. Хәзер инде Сабан туе да үтми. Заманасында Рәмзиянең беткән авылга кияүгә чыгуына күпләрнең исе киткән. Янәсе, укытучы башы белән шунда бармаса? Үкчәле туфли киеп, күкрәк киереп, фырт итеп йөрерлеге бар бит. Тик Рәмзиянең сүзе бер була: «Иремне яраткач, аның әти-әнисен дә, туганнарын, авылын да яратырга тиешмен». Авыл урамнарында пычрак ерып йөрү дә, көтү куу, сыер саву да аның өчен газапка әйләнмәгән. Бахтачының һәр сукмагын, җиләкле урманнарын, чишмә юлларын бик тиз яратып өлгергән ул. Ире Ирек белән бергә яши башлавына – 27 ел. Бергәләп өч бала тәрбияләп үстергәннәр. Олы кызы Энҗе «Безнең Мирас» журналында эшли. Илүзә көллияттә – шәфкать туташына, ә иң кечесе Ислам 9 нчы сыйныфта укый. Шушы вакыт эчендә Рәмзия иренә бер генә тапкыр да, авылдан китик, дигән сүзне әйтмәгән. 85 яшьлек каенанасы белән дә уртак тел табып яши. Каенатасы Гаделҗан мәрхүм инде. Кыскасы, гаилә учагының җылысын бергәләп саклыйлар.

Ишегендә – йозак

Бахтачыда башлангыч мәктәп ябылгач, бик борчылган Рәмзия. Борчылмаска, 20 еллап сабыйларны хәреф танырга, язарга өйрәткән мәктәп бит ул. Өчәр сыйныфны бергә кушып укыткан чаклары да булган. Бала саны бергә генә калгач, ишегенә йозак элгәннәр. Инде ничә еллар узса да, мәктәп шул килеш тора. «Бахтачы мәктәбе» дигән язуына кадәр бар. Бүрәнәдән салынган дүрт почмаклы белем йорты төшләренә дә кереп йөдәтә аның. Заманасында берәүнең йорты булган ул. Соңрак мәктәп булып хезмәт иткән. Мичкә ягып җылытылса да, эченнән нур бөркелгән. Балалар шунда укыган, ашаган, физкультурасын да ясаган. Ишегалды чәчәккә күмелеп утырган. Шушы җылы мохитне, бигрәк тә миләшләрен сагына Рәмзия. «Миләшләрем, миләшләрем, түгелә күз яшьләрем…»

Мәктәпнең язмышы да шушы җимеш кебек ачы шул. Нишләтәсең, авылдан читкә бәхет эзләп китүчеләрне дә гаепләп булмый. Һәркемнең – үз язмышы.

Әмма шул вакытта авылда калып, барысына да шөкер итүчеләр дә аз түгел. Авылның да шәһәрдән бер ким җире юк хәзер.

Өй-мәктәп

Мәктәп бетсә, авыл бетә, дигән сүз белән килешә Рәмзия. Әнә бит башлангыч мәктәп ябылгач, әти-әниләр шәһәргә күченә башлаган. Картлар әкренләп бакыйлыкка күчкән. Өйләнешүчеләр дә, бала табучылар да юк. Иң соңгы булып туган балалар да – үзләренеке. Рәмзия – үз авылының патриоты. Мәктәп ябылганга борчылса да, кул кушырып утырмый, ниндидер чарасын таба. Каената-каенанасы, иренең рөхсәте белән үз йортларында авыл балаларын укыта башлаган. Янгын сүндерүчеләр, СанПиН белгечләре килеп, өйдә укытырга ризалык биргән. Парта, такта куялар… Шулай итеп, өйнең бер бүлмәсе мәктәпкә әйләнә. Бер генә түгел, 13 елга! Авылдашлары Хөсәеновлар йортын «өй-мәктәп» дип йөрткән. Башта күрше кызы Рәниләне, аннан үз балалары Илүзә белән Исламны укыткан. Шәһәрдән кайткан Йосыф та йөргән әле «Укытучы йорты»на. Тик сыйныфта бала саны 1–2дән артмаган.

– Дәрес сәгать 8дә башлана иде. Балалар безгә һәрвакыт букча тотып, мәктәп киеменнән йөрде. Балаларга һәр фәнне җентекләп аңлатырга тырыштым. Үз балаларыма да кагыйдәләр бер төрле иде. Таләпчән һәм гадел булдым. Алар миңа «апа» дип түгел, «әни» дип дәште, – дип искә алды ул өендә укыткан елларын.

…Бүген инде Рәмзия Хөсәенова мәктәп ябылу, авылда йортлар саны кимү турында да түгел, туган тел язмышы, әлеге дә баягы татарча белмәгән укучылар турында борчыла. Әти-әнисе татар булып бит ул! Гаиләдә бер авыз сүз русча сөйләшмичә… Шәһәрдәге шаукым авылга килеп җиткән түгелме? Монда, телевизор руслаштыра, дип гаепләп тә булмый. Әти-әни дә, гаилә дә тел мәсьәләсендә нык торырга тиеш. Карлы сукмактан күрше Күлле Киме мәктәбенә барганда һәм кайтканда укытучының уйлары – бары шул хакта. Их, нинди дә булса чишү юлын табасы иде бит… Мәктәп, гаилә белән бергәләп. Гомер буе телне, гореф-гадәтләрне саклаган авыл үз кыйбласын югалтмасын иде.

Авыл, тел язмышы өчен борчылып яши Рәмзия Хөсәенова.

Сәрия МИФТАХОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Төбәкара хезмәттәшлекне ныгытудагы казанышлары һәм Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башлыгы **Иванов** Анатолий Петрович **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Республиканың тарихи-мәдәни һәм рухи мирасын саклауга, торгызуга һәм популярлаштыруга мөһим өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы башлыгы **Афанасьев** Михаил Павлович, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Халыкара мөнәсәбәтләр институты директорының фәнни эшчәнлек буенча урынбасары **Вәлиев** Рафаэль Миргасыйм улы, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директорының Төркия Республикасында проектларны үстерү буенча киңәшчесе **Гыйматдинов** Радик Рөстәм улы; республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Динамо-Казан» хатын-кызлар волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы командасы башлыгы **Лебедев** Андрей Александрович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Җирле үзидарә органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Бөгелмә шәһәре мэры урынбасары **Белова** Ирина Борисовна; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының халыкара элемтәләрне үстерү бүлеге башлыгы **Галиева** Рената Мөбарәк кызы, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалы директоры **Костин** Артем Петрович; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «БЕРДӘМ РОССИЯ» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлекчәсе Төбәк башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – оештыру эше бүлеге башлыгы **Смирнова** Светлана Александровна; республиканың җылылык-энергетика комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Энергопрогресс» инженерлык үзәге җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык техникасы җайланмаларын көйләү һәм сынау хезмәте башлыгы урынбасары **Шәрифуллина** Равилә Наил кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге башлыгы **Гаврилов** Владимир Иванович, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы **Гайнуллин** Фәнис Рафикъ улы, «Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесенең оештыру бүлеге башлыгы **Желавская** Оксана Александровна, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге башлыгы **Нәфыйков** Габделфәт Шәмселгариф улы, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Яңа Үргәагар авыл җирлеге башлыгы **Рәхимҗанов** Әнвәр Әдһәм улы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башлыгы урынбасары **Сәмигуллин** Ришат Роберт улы, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Хәбибуллина** Рушания Морат кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе **Михайлова** Зөлфия Габделхәмәт кызы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Архангел авыл җирлеге башлыгы **Сердюк** Нина Анатольевна **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илленче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы илленче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләр раслау хакында» 516-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 515-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 514-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 497-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 509-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Аерым муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 513-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 501-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
10. «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 517-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 512-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
12. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 511-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 498-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 510-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
15. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 508-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны үткәрү өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында.
17. Ганиев Илшат Газыйм улының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.
18. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты составындагы үзгәреш турында.
19. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетының 2019 елның сентябреннән 2023 елның декабренә кадәр чордагы эше турында хисабы.
20. 2024 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында.
21. 2024 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы турында.
22. «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 10 пунктының һәм 83 статьясындагы 9 өлешенең конституциячел булуын тикшерү хакында гарызнамә белән Россия Федерациясе Конституция Судына мөрәҗәгать турында.
23. Татарстан Республикасында җәмәгать юстициясе эшчәнлеге турында мәгълүмат.
24. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 481609-8 номерлы федераль закон проекты турында (полиция органнары һәм контроль (күзәтчелек) органнары вәкаләтләре кабатлануны бетерү хакында).
25. «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 470805-8 номерлы федераль закон проекты турында (һөнәри керемгә салым түләүгә күчү тәртибен үзгәртү хакында).
26. «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүгә һәм аларның әйләнешенә дәүләт контроле турында һәм алкогольле продукция куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында һәм алкогольле продукцияне федераль махсус маркалар белән маркировкалау экспериментын үткәрү хакында» Федераль законның 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 500091-8 номерлы федераль закон проекты хакында (эксперимент үткәрү срогын озайту өлешендә).
27. «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Административ суд эше кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 333901-8 номерлы федераль закон проекты турында (балигъ булмаганнар һәм аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) белән профилактик эш буенча вәкаләтләрне киңәйтү өлешендә).
28. «Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында хезмәт итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 494429-8 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнары хезмәткәрләренә карата чикләүләрне һәм тыюларны төгәлләштерү өлешендә).
29. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында авыл территорияләрен комплекслы үстерү турында».
30. 2023 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.
31. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2271-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп өч елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Алабуга суд районы буенча:

1 нче суд участогына – Динисламова Лилия Фатыйх кызын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Мәскәү суд районы буенча:

4 нче суд участогына – Гаффаров Марсель Барый улын.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп вәкаләтләре чоры чикләнмәгән вакытка түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Югары Ослан суд районы буенча:

1 нче суд участогына – Гарифуллин Рәсим Рәшит улын;

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча:

18 нче суд участогына – Сафина Резеда Равил кызын.

3. Әлеге карарның 2 пункты нигезендә сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының вәкаләтләре чоры алдагы вәкаләтләре чоры тәмамланган көннән башлана.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2272-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының 7^1 статьясы һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

Татарстан Республикасы Арча суд районы буенча 1 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруны бер елга отставкадагы судья Вәлиева Гөлназ Дамир кызына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2273-VI ДС

АО «Татэнергосбыт» уведомляет, что в соответствии со Стандартами раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии, утвержденными постановлением Правительства РФ от 21.01.2004 N 24, на официальном сайте АО «Татэнергосбыт» tatenergosbyt.ru размещена информация о ценах и объемах электрической энергии каждого свободного договора купли-продажи электрической энергии, зарегистрированного гарантирующим поставщиком на оптовом рынке в отношении его зоны деятельности, а также величина корректировки составляющей предельного уровня нерегулируемых цен при учете свободного договора купли-продажи электрической энергии, определяемая коммерческим оператором оптового рынка в соответствии с договором о присоединении к торговой системе оптового рынка.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Акча кирәк

Без хәзер акчаның ни дәрәҗәдә мөһим нәрсә икәнен яхшы аңлыйбыз. Аңлаттылар. Тормыш та адым саен шуны төшендереп тора: өеңнән чыгып, бер-ике адым атладыңмы, акча кирәк. Өеңнән чыкмасаң да кирәк. Сау-таза булсаң да, авырып ятсаң да, хәтта үлеп-нитеп китсәң дә. Кыскасы, бу дөньяда адәм баласының акчадан да кирәклерәк нәрсәсе юк.

Шуңа күрә без аны күп итеп табарга, беркайчан да бетмәслек итеп җыярга тырышабыз. Шуның өчен төрле этлекләргә барабыз, кайчандыр изге булып тоелган хыялларыбызны таптап китәбез, сәламәтлегебезне дә, гомеребезне дә шуның хакына корбан итәбез. Сәламәтлекне иртәгә дә төзәтеп була, ә акча бүген кирәк. Гомер дә бушка бирелгән, бушка килгәч, ул Идел суы сыман мәңге бетмәс кебек тоела. Ләкин сәламәтлек тә, гомер дә бетә. Ә акча җитми.

Бөтен нәрсәне дә алдан күреп, егыласы урыннарның барысына да салам җәеп бетереп булмый. Хәтта андый мөмкинлегең булганда да кайбер урыннарга мендәр, кайберләренә келәм җәяргә тырышасың, шуннан саламга да җитми кала. Кыскасы, бер мәлне минем дә акча бетте. Телефонда.

Авылга кайткан идем. Автобус белән генә. Алдан түләп куя алмаганмын инде. Онытылган. Ә авылда бернинди терминал да, бүтән кирәк-ярагын да әзерләп тормаганнар. Интернетка кереп, акча күчерү өчен телефон кирәк, ә телефонда акча булмагач, интернет-банкка да керә алмыйсың. Кулыңдагы акчага карап тилмереп утырырга туры килә. Район үзәгенә төшсәң, ерак кына. Хатын эштә, трубканы алалмый. Малай юлда, поездда кайтып килә, телефоны тотмый.

Сөенечле хәл түгел инде бу. Тик утырып еларлык зур кайгы да түгел. Дуслар бар, танышлар бар. Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын, дип халык та белми әйтмәгәндер. Хәер, анысына да тулысынча ышанып булмый инде. Халык авызыннан үзең тәгаен ишеткән нәрсә түгел бит, кеше сүзе генә, ә кеше сүзе гайбәт тә булырга мөмкин. Тик шулай да өмет бар. Дуслар булган җирдә өмет була, монысын үзем кичереп беләм.

Вәт, шундый уйларга бирелеп өч-дүрт минут торганнан соң, колхоз телефоныннан бер дуска шалтыратам. Бу сөенә инде, дуслар шалтыратканда һәрвакыт сөенәсең, ә ул дустың берни дә сорамаса, шатлыгың икеләтә арта. Шатлыгы балалый башлаганчы дип, мин үз үтенечемне җиткерергә ашыгам:

– Минем телефонга берәр мең салырга кирәк иде. Соңрак мин сиңа күчерермен.

Бу инде шундук ризалаша:

– Ярый, туган, салырмын. Без проблем!

Чынлап та зур проблема түгел инде бу: ул минем телефонга сала, интернетка керү мөмкинлеге ачылгач, мин аңа күчерәм. Ләкин шундый вак кына тоелган нәрсә дә минем зур проблеманы хәл итә. Дуслар булгач, рәхәт. Ул арада икенче дус шалтырата:

– Авылга кайткансың икән, дус, – ди. – Кичке якта кагылып чыгармын, әлегә район үзәгендә йөри идем.

Мин моңа да үз зарымны әйтергә ашыгам:

– Район үзәгендә булгач, берәр мең сал әле минем телефонга. Кичкә акчаңны биреп җибәрермен.

– Яхшы, дустым, – ди бу. – Салырмын. Кичкә керәм, бераз сөйләшеп тә утырырбыз.

– Кер, әлбәттә, – дип сөенәм мин дә. – Хәзер кибеттән урап киләм.

Дус кайтуга берәр каты чәй алып куярга дип кибеткә атласам, яныма бер машина килеп туктый. Күрше икән, район үзәгенә китеп бара. Хәл-әхвәл белешкәч, аңа да зарны сөйлим һәм акча сузам:

– Мә әле, минем телефонга да салып кайт...

Бу баш тарта:

– Ярый, кайткач бирерсең... Әлегә акча җитәрлек...

– Төрле чагы була, мә ал әле...

– Юк, борчылма, эшләп торабыз бит...

Кибет алдында тагын бер дус очрый... Шул рәвешле, урап кайтуга очраган бөтен дуска йомышымны җиткерәм. Барысы да ризалаша. Шуннан мин нәрсәнедер исемә төшереп, сискәнеп китәм. Шайтан алгыры! Артыграк кызып киткәнмен бит... Соң хәзер боларның барысы да җыелып килсә, ким дигәндә ун мең сум чамасы чыгарып бирергә туры киләчәк бит. Бер телефон өчен. Район үзәгенә такси белән барып кайтсам да, арзангарак төшәр иде.

Адәм баласы кызык бит ул. Хәзер инде мин, әлеге дусларның барысы да акча салмаса ярар иде, дип тели башлыйм. Күрше онытырга мөмкин, үз мәшәкатьләре артыннан йөрсә, акчасы да җитмәскә мөмкин. Теге дус та өлгерә алмаска мөмкин. Шулай булса гына ярар иде. Югыйсә тик торганнан гына телефон өчен ун ай алдан түләп куясы килми. Монда да чыгымнар күп бит әле. Тик шикләнеп тә куям. Егетләрнең барысы да ышанычлы, сүзләрен җилгә җибәрә торган кешеләр түгел. Бөтен ышаныч Ходайда инде. Ә мин телим. Һич югында бер-икесе генә акча салсын иде, дим.

Ходай Тәгалә дә кайчагында минем сүзләргә колак сала бугай. Һәрхәлдә, ара-тирә минем теләкләр дә үтәлә. Бу юлы да шулай булып чыкты. Теге дусларның берсе дә акча салмаган. Кайсы онытып җибәргән, кайсы нәрсә... Ә мин сөендем генә.



КАЙСЫНДА «АЛТЫН...» КҮБРӘК?

24 НЧЕ «ТАТАР ҖЫРЫ»НЫҢ ИСТӘ КАЛГАН МИЗГЕЛЛӘРЕ

Дубайдан кайткан Илназ, рекордчы Айдар Галимов, Ришаттан Маратка күчкән кызлар. Быелгы «Татар җыры-24» фестивале, мөгаен, әнә шулар белән истә калгандыр. «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгенең Илһам Шакиров исемендәге концерт залында узган тамашаны 2,5 мең ярымга якын халык белән бергә «ВТ» хәбәрчесе дә карады.

Декабрь ахырында эстрадада төп вакыйга булган «Татар җыры» фестивален карау күпләр өчен традициягә әйләнде. Шул исәптән журналистларга да. Алдагы елларда матбугат очрашуы оештырып, концертның яңалыклары, үзенчәлекләре белән уртаклашсалар, быел алай итеп тормадылар. Концертның үзендә дә әллә ни үзгәрешләр күрмәдек. Нигездә, бар да элеккечә иде. Билет бәяләре «тешли» торган, уртача алганда 4–5 мең сумнан узып китсә дә, залда буш урын булмады диярлек. 4,5 сәгать барган тантана җырларга заманча яңгыраш бирүче «Зәкәрия» фолк төркеменең төрле телләрдә попурри башкаруыннан башланды.

Кешене киеменә карап каршы алабыз бит инде. Артист халкын бигрәк тә. Шуңа бу теманы да читләтеп узып булмас. Беренче бүлектәге бөтен җырчы карадан, актан яки аклы-каралыдан чыкса, икенчесендә ялтыравыклы костюм-күлмәкләрдән иделәр. Гаҗәп түгел, бу сезонда алтын һәм көмеш төсләр модада бит.

«Татар җыры»н Гөлназ Сәфәрова, Рамил Шәрәфиев һәм Айрат Ильясов алып барды. Шунысына игътибар иттем: алып баручыларның елдан-ел сүзләре кими бара кебек, мәзәкләр дә азрак яңгырады. Бер яктан караганда, бу бик яхшы. Җыр тыңларга килгән тамашачыны озын-озак сүзләр, урынсыз шаярулар белән ялыктырмадылар. Истә калган берничәсен генә әйтеп узам: ел дәвамында халык телендә йөргән вакыйгалар – Ришат белән Тәтишканың кавышуы, Дубайга юлламалар, Ришат Төхвәтуллинның Марат Яруллинга күчкән фанат кызлары, Илсөя Бәдретдинованың концертта әллә ничә төрле күлмәк алыштыруы, Илмира Нәгыймованың кияүгә чыгуы турында булды.

Артистлардан беренче булып хатын-кызлар арасында популяр булган җырчы Әнвәр Нургалиев чыкты. «Барс-Медиа» компанияләр төркеме директорлар шурасы рәисе Камил Гәрәев кулыннан сәхнәдә «Алтын барс» сынын алган бердәнбер җырчы булды ул. Калганнарга сәхнә артында гына өләштеләр.

Алып баручылар «Алтын барс»лы булуны Олимпия уеннарында алтын медаль алу белән тиңләделәр. Һәр ел фестивальдә 30дан артык җырчы катнаша. 24 ел эчендә 700дән артык «Алтын барс» сыны бирелгән дигән сүз бу.

Кайсы җырчыда алтын күбрәк һәм кайсы иң бае? Айдар Галимов икән. Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты быел 24 нче тапкыр фестиваль лауреаты булды. Җырчы сәхнәдә иң күп бүләк алучы да булгандыр әле. Кочак-кочак чәчәк бәйләмнәренә күмделәр үзен.

Беренче «Алтын барс»ын алган җырчылар өчен дә сөенеп утырдык. Шундыйлардан, әйтик, Сиринә Зәйнетдинова. Тамашачы күңелен «Балам» җыры белән яулап алды ул. Руслан Кираметдинов белән дуэтын да яратучылар күп. Сер түгел: быелгы «Болгар радиосы» Милли музыкаль премиясендә Руслан Кираметдинов булмаганга, халык бик борчылган иде. Хәзер күңелләре тынычлангандыр, шәт.

Әтиле-уллы Илназ һәм Зиннур Сафиуллиннар икесенә бер статуэтканы бүлде. Илназ «Татар җыры» өчен Дубайдан махсус кайткан. Алып баручылар да бу хакта телгә алмыйча булдыра алмады. Айрат җылы якка барасы килүен әйткәч, Гөлназ: «Казан блогерлары 5 меңгә Дубайга путевка сатканда алган идең бугай, бармадыңмы?» – диде. «Ярты зал да алган, ахрысы. Ап-ак загарлары белән утыралар әнә», – дип төрттерде Айрат Ильясов. Кызык та, кызганыч та. Әтиле-уллы җырчылар сәхнәдә Зиннур Сафиуллин язган популяр җырлардан торган попурри башкарды.

Күптән түгел хастаханәдә ятып чыккан артистлар да, тернәкләнеп, «Татар җыры» сәхнәсенә чыгып басканнар иде. Тәне пешеп, Теләчедә дәваланып кайткан Илнат Фәрхуллин сикерә-сикерә җырлады. Декабрь башында реанимациягә эләккән Ришат Фазлыйәхмәтов та «в строю» иде.

Концерт дәвамында берничә җырчы үзенә хас булмаган образ, стильдә чыгыш ясады. Мәсәлән, классик, озын күлмәкләрдән күрергә күнеккән Эльмира Кәлимуллина тамашачыны кыска, ялтыравыклы күлмәге белән гаҗәпләндерде. Данир Сабиров башта моңсу җыр җырлады. «Заманалар үзгәрә, мине дә моңсу җырлар белән «Татар җыры»на чакыра башладылар», – дип шаяртты. Икенче итеп, үзенә күбрәк хас булганча, күңелле җыр башкарды. Әллә ни кул гына чапмадылар. Моны үзе дә сизде, ахрысы: «Әллә Рөстәм Нургалиевич булганга оялалар шунда, гадәттә, алай түгел иде минем концертларда», – диде, җырлап бетергәч. Ә концертта иң эмоциональ чыгыш Азат Фазлыевныкы булгандыр, мөгаен. Татар эстрадасының «буйдак красавчигы» Марат Яруллин да кимен куймады. Башта кызларны үзенә гашыйк иткән, хәзер инде камыт кигән Ришат Төхвәтуллин «подписчик»ларының хәзер Марат Яруллинга күчүе турында да шаярулар булды.

Яңа гына өч айлык гастрольләрдән кайтып төшкән Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар да – фестивальнең яңа лауреатлары. Гадәттәгечә, матур, күңелгә үтеп керерлек итеп җырладылар. Аннан бигрәк, тамашачының күбесе, бигрәк тә ир затыннан булганы Зөлфирәнең тирән декольтелы күлмәген истә калдыргандыр. Алмаз Мирзаянов исә репертуарларында Зәйнәб Фәрхетдинованың «Ялгызлык утында янмагыз» җыры алдыннан гел дулкынлануын әйтте.

Концертта яшьрәкләр мәхәббәт, Татарстан табигате турында җырласалар, легендар Зөлфәт Хәким, Салават Фәтхетдинов, Идрис Газиевның җырлары тантанага тирәнрәк мәгънә өстәде, әчтәлеген баетып җибәрде. Милли башланган тамаша шулай тәмамланды да. Филүс Каһиров белән Марат Галимов башкарган «Татар телем» җырына барлык зал аягүрә басып, кушылып җырлады.

Ләйсән САФИНА

Язмыш

ГОМЕРЛЕК ЯРА

Сәламәтлегемдә тайпылышлар бар, ди ул. Ә фикерләре буенча аннан да акыллы кеше юк, диярсең. Арчада яшәүче Тәнзилә апа Закирова белән аралашкан саен, шундый фикергә киләсең. Дөресен генә сөйли, башкалар яхшы атлы булып калу өчен дәшми калганны да курыкмыйча әйтә, ул сөйләгәннәр һәрчак дөреслеккә дә туры килә. «Эшең уң барсын, дисәң, мине рәнҗетергә кирәкми», – ди ул. Кечкенә генә яхшылык эшләсәң дә, бөтен күңеле белән сиңа изгелек тели. Ә ачуын китермәвең хәерлерәк...

Беркөн Тәнзилә апа белән озак кына сөйләшеп утырдык. Аны районда заманында танылган киномеханик буларак яхшы беләләр. Әмма без сүзне ул кысада гына алып бармадык, шушы изге күңелле апаның язмышына «сәяхәт кылдык». Ул сөйләгән саен, «нинди генә язмышлар юк» дигән сүзләрне кат-кат кабатлыйсы килә. Бер очрак, бары бер очрак гөрләп яшәп ятучы кыз баланың тормышын бөтенләйгә үзгәртә дә куя.

– Тугач та, әни мине әбигә калдырып, кияүгә чыгып киткән. «Миннән артмый», – дигән әби җаным. Өйдә әле ике килен бар. Шулар арасында үстем инде мин. Берсен дә яманлыйсым килми, чөнки әби бервакытта да минем турыда «артык тамак» диярге урын калдырмады. Ул миңа бөтен назын бирде, көченнән килгәнчә киендерде (тегә иде), кадерләде, тамагым тук булды. Мәктәптә «бишле» билгеләренә генә укыдым. Немец теленнән генә «бишле» була алмады, авыр бирелде ул. Укытучылар һәръяклап ярдәм итте. Киемнәргә кадәр бирәләр иде. Сәлих Гәрәевичка мин гомерем буе рәхмәтлемен, – ди Тәнзилә апа.

12 яшеннән эшли башлый кыз. Каникул җиттеме, колхоз эшенә чыга. Төшкә кадәр мәктәптә булса, төштән соң эшкә чыгып чаба. Унынчы сыйныфны тәмамлаганнан соң, киномеханик һөнәрен үзләштерү максатыннан читтән торып техникумга укырга керә. Ә үзе колхозда хезмәтен дәвам итә. Мәктәптә ничек укый, эштә дә шундый була ул. «Ат кебек эшли», – диләр андыйлар турында. Төксерәк яңгыраса да, дөресе шул бит. Үзен аямый ул. Ни кушсалар, кая җибәрсәләр, шунда йөгерә. «Юк» дигән сүзне бөтенләй белми.

– Колхоз рәисе Мирзаян Вахитов гел мактап килде. «Тәнзиләгә җитеп карагыз», – дип, мине башкаларга үрнәк итеп куя иде. Син генә булдырасың, дия иде эшкә кушканда. Клеверын да, борчагын да чаптым. Барысын да булдырдым. Депутат та булдым, бүләкләр дә алдым, район слетларында да катнаштым, рәсемем мактау такталарында да торды. Кичләрен сәхнәдән төшмәдем. Җырлый идем мин. Дипломант исемен дә яуладым. Спектакльләрдә дә уйнадым, – дип искә төшерде яшь чагын Тәнзилә апа һәм бу вакытта аның йөзе тагын да яктырып киткән кебек булды. – Аннан төзелешкә киттем. 1971 елда әби үлде. Берьялгызым калдым. Тирә-юнем караңгылыкка чумган кебек булды. Әмма үземне кулга алдым. Ялгыз дип тормадым, терлеген дә асрадым, бәрәңгесен дә утырттым.

– Очрашып йөргән егетегез бар идеме соң, Тәнзилә апа? – дип сорыйбыз.

– Бар иде. Арча районының бер авылыннан иде ул. Мәктәптән соң югары белем алды. Минем кебек белемсез кыз кирәк түгел, дип ишеттерде. Бик авыр булды, әмма сер бирмәдем, – диде Тәнзилә апа.

– Башка очратмадыгызмы аны?

– Элек оешмаларда эшләгәннәрне колхозга бәрәңге алырга җибәрәләр иде. Кунып кайткан чаклар да булды. Мин шул егет яшәгән авылга туры килдем бит. Кызыксынып сораша торгач, әлеге егетнең эчә башлавы, тәмам түбән тәгәрәве турында ишеттем. Аның шундый хәлгә төшүенә сөенгән, дип кабул итә күрмәгез тагын, шулай да күңелдә тантана булып алды. Мин белемсез булсам да, төшеп калмадым, тырышып хезмәт иттем, макталып килдем, – диде ул.

Чыннан да, кайда гына булмасын, иң авыр участокларда эшли ул. Ирләр белән беррәттән, аларны да уздыра. Бакчасын да казый, карын да көри, түбәгә менеп кар да төшерә. Ике тапкыр биектән егылып төшеп, фәрештәләр канаты астында кала. Ә менә өченчесендә... Анысы Тәнзилә апа өчен аяныч тәмамлана.

– Ни хикмәт, өчесе дә атнакичкә туры килде. Өченчесендә оешма конторасы түбәсеннән егылып төштем мин. Башым белән. Ниләр кичергәнемне үзем генә беләм. Аны сүз белән генә аңлатып бетереп булмый. Минем йөрәгемдә төзәлмәслек бер яра булып калды ул. Шуннан егыла торган авыру белән калдым. Озак еллардан бирле группада мин. Ул чакта, йөрәкне тагын да җәрәхәтләп, Зур Бирәзәдә кыйнаганнар, дип тә сүз чыгардылар әле. Кешенең күңелен күр син!

Әбисе вафат булганнан соң, кинофильмнар куярга хокук биргән таныклыкны кулына ала Тәнзилә апа. «Колос» мәдәният йортына эшкә керә. Шул көннән башлап бик озак еллар язмышын кино хезмәтенә багышлый.

– 1964 елда билет сата башласам, 1968 елда кино күрсәтә идем инде. Эшемне бик яраттым, – ди.

Тәнзилә Закирова Казаннан, Нократ Аланыннан, хәтта Канаштан кинотасмалар алып кайткан.

Тәнзилә апа – Россиянең атказанган кинематографисты! Казаннан, Нократ Аланыннан, хәтта Канаштан алып аллы-артлы кинотасмаларны асып кайткан бит ул.

– Көндезге икегә дип афиша эләм. Шул вакытка кайтып җитәргә кирәк. Электричкадан җәяү шактый барасы. Җилкәмә аскан йөгем кайчак йөз килограммга кадәр җитә иде. Яхшыларын гына алам. Кайберләрен мин беренче булып күрсәтәм. Халык йөри, карый, рәхмәт әйтә. «Колос»та алай эшли алмыйсың, анда кеше йөрми, диде җитәкчеләр. «Акчаны үзеңә калдырмаска кирәк. Бары шул гына», – дидем. Планны 148 процентка үтәдем, – диде Тәнзилә Закирова.

Тик киномеханикның хезмәт хакы аз, ялгызы гына булса да, тормыш итәргә кирәк. Фатир ала, аңа да түлисе бар. Тәнзилә апа кешеләргә бакча казый. «25 сутыйны бер тотынуда бетерә идем. Төне буе казыйм», – ди ул. «Сезнең фатирында булганыгыз бармы? Андагы чисталыкка исең китәрлек», – диде бервакыт бер ханым. Бу хакта әйткәч, Тәнзилә ханым елмаеп кына куйды. «Бер кунакка килерсез әле», – диде.

Бер риясыз җан инде ул. Дөрес итеп кабул итәргә генә кирәк аны. Кешеләрнең күңелен күрергә тырыша. Радиога котлаулар бирә ул. «Ике меңнән артык котлавымны тапшырдылар инде. Кешене сөендерү үзе рәхәт бит», – ди. Өлкәннәр көненә безгә конфетлар алып төшкән. Ул – безгә. Үзенә кечкенә генә күчтәнәч бирсәң дә, сабый бала кебек сөенә. «Алланың рәхмәтләре яусын сезгә. Тигезлектә яшәгез. Бала хәсрәтләре күрмәгез», – дип теләкләрен җиткерә. «Минем теләкләр кабул була», – дип өсти соңыннан. Үзегезгә тыныч көннәр телибез, Тәнзилә апа. Картлык, дип әйтмибез, чөнки ул үзенең яшен күрсәтергә яратмый. Һәрчак шулай яшь күңелле булып калсын.

Гөлсинә ЗӘКИЕВА

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кышкы шигырь

Кар – әйтерсең ап-ак кәгазь,
Теләсәң – шигырь,
теләсәң җыр яз!

Нур каләмен кулына тотып
Чыгып баскан шагыйрь – кояш.
Кыш иртәнге җиле белән
Карны өерә җиңел генә.
Нурга төренеп, карлар оча,
Бу ичмасам шигырь менә!..

Аны зәңгәр урман укый,
Бөдрә карлы кырлар укый.
Чыршы кызы җырлап утыра,
Ә, күрәсең, ул да укый.
Яшел бәрхет күлмәк кигән,
Итәкләре җиргә тигән.

Беләм, беләм,
Кояш менә
Шушы Чыршы кызын сөя.

Муса ҖӘЛИЛ

Нәҗибә апабыз

Беркөн Мәдәният сараенда шөһрәтле якташыбыз, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Тукай премиясе лауреаты Нәҗибә Ихсанова турында фильм карадык. Тамашачы бик аз иде. Чөнки халык белми калды. Без дә шул көнне генә белдек. Мәктәптән ихтыяри-мәҗбүри килгән бармак белән санарлык өлкән сыйныф укучыларының яртысы киноның уртасыннан чыгып китте. Рәхмәт инде, хет телефоннарында уйнап, шаулап, безгә комачауламадылар, тыныч кына чыгып югалдылар. Ә без, бер төркем пенсионерлар, экраннан күзебезне алмыйча, һәр сүзен йотып, дөньябызны онытып, тын да алмый карадык. Нәкъ бер сәгать барган документаль кино безгә җитмәде. «Бәй, бетте дә мени?» – дип таралышасы килми тордык. «Бер сәгатьтән артмаска тиеш булгандыр», – дигән нәтиҗә ясадык үзебезчә.

Күп еллар элек Кәрим Тинчурин исемендәге театрда якташлар очрашуына җыелгач, Нәҗибә апа белән икәүдән-икәү бер аулак бүлмәдә хәтсез генә сөйләшеп утырган идек. Шунда аның: «Туфан – туфан инде ул», – дигән сүзләре күңелемә кереп калды. Ире, танылган драматург Туфан Миңнуллинның (исеменә кара син – давыл, көчле ташкын дигәнне аңлата) туры сүзле, батыр йөрәкле, курку белмәс кеше икәнен бөтен республика белә иде.

Яңадан бер очрашкач, Нәҗибә апа «Нәсимә якташыма зур хөрмәт белән, Нәҗибә Ихсанова. 18 февраль, 2008» дип язып, «Уйнап узган гомер» дигән китабын бүләк итте. Йөгерек тел белән язылган, бихисап фоторәсемнәр белән баетылган автобиографик бу китап буенча да, телевизордан күргән интервьюлар һәм әдәби-театраль очрашулар буенча да күренекле якташыбыз турында бөтенесен беләм сыман иде. Юк икән…

Фильмның режиссеры Алмаз Нургалиев һәм аның иҗат төркеме шаккатырды! Җиңел юл белән бармаганнар. Күп җирләрдә булганнар, 15–20 кеше белән әңгәмә корганнар һәм бу интервьюларны җайлы итеп, тулаем гына бирмичә, вак кисәкләргә бүлгәләп, йөзләгән «пазл»ларны урынына карап сайлап, тирән эчтәлекле, дәлилле әйбәт фильм ясаганнар. Күңел биреп, яратып эшләгәннәр. Нәҗибәнең, Туфанның, азнакайлыларның, дусларның, туганнарның, коллегаларның сүзләре үрелеп, бер-берсен тулыландырып бара. Вак детальләрдән бу ике бөек шәхеснең холкы да, зур таланты да, үзара гармониясе дә ачыла. Кадрия Идрисованың истәлекләрен тыңлаганда, кара, ничек зирәк акыллы булган безнең Нәҗибә апа, дип исем китте. Андый мизгелләр тагын да булды.

Рәхмәт якташыбыз турында шундый яхшы фильм төшергән өчен! Бу киноны бөтен татар күрсен иде! Шәхесләребезне без белергә, танытырга һәм горурланырга тиешбез.

Нәсимә КАМАЛИЕВА.
Азнакай

КЕМ НАЧАР УКЫЙ – ЧҮПРӘЛЕГӘ...

ИЛГИЗӘР ХӨСНЕТДИНОВ БУ СҮЗЛӘРГӘ ИГЪТИБАР ИТМИ

Чүпрәле районы халкы Казан шәһәрен элек радиодан ишетеп һәм газета битләреннән укып кына белгән. Зур төзелешләр башлангач, Чүпрәле халкы Ульяновск ягына агылган. Эшчеләр кирәк булгач, аларны, машиналар биреп, хәтта йорт-җирләрен төяп күчерәләр. Шулай итеп, яңа бистәләр барлыкка килә.

Туган яклары белән элемтә өзелмәсен өчен, Чүпрәле районының һәрбер авылына автобус маршрутлары ачыла. Ә район үзәгенә көненә 18–20 рейс автобус йөри. Кышларын АН-2 самолеты оча.

Чүпрәле мәктәпләрен яхшы укып тәмамлаучы егет-кызлар арасында, белемгә омтылып, Казанга китүчеләр, институтларга укырга керүчеләр дә була. Андыйлар арасында Кече Чынлыдан Илгизәр Хөснетдинов та бар. Ул яшь вакытыннан авылда табиб булырга хыялланып үсә. Чөнки ул елларда шәфкать туташлары да җитәрлек булмый. Илгизәр медицина институтына укырга керә. Бик тә актив студент була, яхшы укый, спорт ярышларында катнаша. Чаңгы шуу һәм йөгерү буенча икенче һәм өченче разрядлар ала. Ул елларда доцентлар һәм профессорлар: «Кем начар укый, институт тәмамлагач, юллама белән Чүпрәле районына җибәрәчәкләр», – дип куркыта. Чөнки монда юл, газ, асфальт юк, район үзәгендә – балчык, җәен халык кирза итектән йөри. Илгизәр үзе Чүпрәледән булгач, бу сүзләргә игътибар итми. 1986 елның июль аенда терапевтлар әзерләү бүлеген тәмамлап, диплом алып чыга. Уку белән беррәттән Казан шәһәренең 17 нче хастаханәсендә медбрат булып эшли. Ә инде юллама белән аны Горький өлкәсенең Павлово шәһәренә терапевт итеп җибәрәләр. Тик кайда гына эшләсә дә, хыялы һәм планы ничек тә туган ягына кайту була. Үз теләгенә ирешә ул. Бер елдан Шәйморза авылының участок хастаханәсенә табиб-терапевт булып урнаша һәм соңга таба үзе җитәкче була.

1996 елда Илгизәр Рөстәм улын район үзәк хастаханәсенең терапия бүлегенә җитәкче итеп күчерәләр һәм баш табиб урынбасары итеп куялар. Ике эш тә бик җаваплы була. Ул җиң сызганып эшли башлый. Беренче чиратта, әлбәттә, авырулар. Һәрбер авыру янында булып, хәлен сораша, кан басымын, температурасын үлчи, йөрәген тыңлый, матур сүзләр белән күңелләрен күтәрә, өмет өсти. Һәр авыруга дарулар язып калдыра да, шәфкать туташына тапшырып, поликлиникадагы кабинетына йөгерә. Аны инде ишек төбендә 20–30лап авыру көтә. Аларны кабул итәр өчен күпме түземлек, сабырлык, күңел күтәренкелеге кирәк бит. Кич белән юл уңаеннан тагын хастаханәгә кереп, авыруларның хәлләрен белешеп чыга.

Соңгы ике елда коронавирус белән авыручылар турында аерым әйтәсем килә. Районда 21 мең 500 кеше яшәп, вирусны йоктырмаган кеше калмагандыр. Бүген исән-сау яшәвебез өчен

без барыбыз да Илгизәр Рөстәм улына рәхмәтле. Андый авыруларны хастаханәдә бары ул кабул итеп, карап, тикшереп, кайсыларын хастаханәдә, ә җиңелрәк авыручыларны өйләренә җибәреп, дарулар белән дәвалады. Ике ел өстеннән вируска каршы тегелгән киемнәрен салмады. Ике ел көн-төн хастаханә бүлмәләрендәге авырулар яныннан чыкмады. Өйләрендә дәвалanучыларга тиешле дарулар язып, телефоннан хәлләрен белеп, киңәшләрен биреп торды. «Югалып тормагыз, минем белән элемтәне өзмәгез», – дип кисәтте. Ничек кенә өлгергән диген?

Илгизәр Рөстәм улы үзе дә: «Авыруларга ярдәмем тигәч, мин бик тә шат, аларның исән-сау булуларына горурланып яшим һәм эшлим», – ди. Хастаханәдән терелеп чыгучыларны матур, ягымлы сүзләр белән озатып кала. «Исән-сау яшә, мин язган дарулардан файдалан. Әгәр хәлең начарайса, элемтәгә чык», – ди.

Илгизәр Рөстәм улы коллективта зур абруйга ия. Баш табиб урынбасары да булгач, һәр табиб, шәфкать туташы белән киңәшләшеп эшли. Аны хөрмәт итәләр, ышаналар. Шуңа күрә профсоюз җитәкчесе итеп сайлыйлар. Эш дәверендә күпләгән бүләкләргә дә лаек була ул. Үзе дә: «Миңа карата булган җылы мөнәсәбәтләрдән, рәхмәт сүзләреннән мин бик тә канәгатьмен. Районда сәламәтлек саклау зур үсеш алды. Халкыбыз исән-сау булсын. Бу – зур байлык. Шуңа күрә без, табиблар, тырышып эшләргә бурычлыбыз», – ди.

Илгизәр Рөстәмович – гаиләсендә дә абруйлы, үрнәк кеше. Тормыш иптәше Дамирә Җәүдәтовна, район хастаханәсендә утыз елдан артык шәфкать туташы булып эшләп, лаеклы ялга чыкты. Улы Булат, урта мәктәпне медальгә тәмамлап, Ульяновск дәүләт университетының медицина факультетын тәмамлады. Рентгенология ординатурасын тәмамлап, Ульяновск клиник хастаханәсендә табиб булып эшли. Кем белә, бәлки ул да әтисе кебек туган ягына юл тотар әле.

Әмир САБИРҖАНОВ.
Чүпрәле

«УРАМА»ДА КЫЗ ЕЛАТАЛАР

Бөтендөнья татар конгрессының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы башкарган эш-гамәлләр – татар милләтенең якты киләчәгенә бер адым ул. Сембер якларында йөреп кайткач, бу фикерләремнең хаклыгына кабат инандым.

Владимир Ленин туган төбәк белән танышу Димитровград шәһәренең 1986 елда төзелгән Җәмигъ мәчетендә башланды. Биредә без, мосафирлар намазы укып, имамнар белән аралашып, фикер алыштык. Аннан «Болгар заставасы» агротуристик тарихи-мәдәни комплексына юл алдык. Биредә күпгасырлык тарихы булган борынгы болгарларның тормыш-көнкүреше белән таныштык.

Күңелне биләп алган хисләрдән айный алмыйча, шәһәр үзәгендәге «Татар авылы» көнкүреше музеена юнәләбез. Түбәләре күккә ашкан йортлар арасында авыл ихатасы! Ишегалды тутырып арба тора. Арбада – хуш исле печән. Ярган утын әрдәнәсеннән агач исе аңкый. Әтием тирә-якта данлыклы балта остасы иде. Балачакта аның алачыгы минем иң яраткан урыным булды. Шулар искә төшеп, күземә яшь килде. Утарның махсус бүленгән урынында үрдәкләр бакылдый, тавыклар кытаклый. Шәһәрдә авылны сагынып яшәүчеләргә, авылдагы әби-бабаларын сагынган оныкларга менә дигән юаныч бу.

Өй эченә үтәбез. Тәрәзәләрдә без килен булып төшкән чактагы пәрдәкашагалар. Ул чакта гаиләләрдә 2–3 килен бергә яшәгән өйнең һәр почмагы чаршау белән бүленгән. Көндез чаршаулар күтәреп куелса да, кичкә гаилә әгъзалары үз чыбылдыгы астында шәхси дөньясына чума, дөньяга тупыр-

дап торган балалар аваз сала. Йорт җиһазлары да борынгы. Шәһәрдәге татарлар кадерле ядкәрләрен монда китерә икән. Ел да җиткән кызлар төп йорт килене кул астында өй юу өмәсе үткәрә. Йола буенча өй матчасын юган кыз шул елны кияүгә чыга, ди.

Ә «Татар утары» ислам мәгарифмәдәни үзәгендә – «Кабак бәйрәме»! Аларның ниндиләре генә юк. Күтәрә алмастай зурлары да, туптай нәниләре дә. Кызлар әни-әбиләре белән бергә кабак бәлеше пешерергә, бөккән ясарга өйрәнә. Без дә телеңне йотарлык шул нигъмәтләрдән авыз иттек. Музей мичендә пешеп, табадан гына төшкән кайнар кабаклы мич коймагы белән дә сыйладылар. Мәхәллә мөслимәләре корган табын янында шушы төбәкләрдә генә җырланучы моңлы мөнәҗәт, бәетләрне тыңлый-тыңлый, әңгәмә кордык, фикер алыштык. Шәһәрнең барлык иҗтимагый оешмалары һәр чараны бер йодрык булып, күмәк башкаралар.

Сәяхәтебезне мәгариф учакларында дәвам иттек. Димитровград шәһәрендәге Габдулла Тукай исемендәге татар мәктәбенең даны еракларга билгеле. Биредә «Иң яхшы татар теле укытучысы» бөтенроссия конкурсы лауреаты Гүзәл Сәмигуллина укучылары республика бәйгеләрендә җиңү яулый. «Очкынкай» балалар бакчасында төрле милләт балалары тәрбияләнә. «Әтиләр», «Әниләр», «Әбиләр» мәктәпләре эшли. Аларның һәркайсы үз ана телен, гореф-гадәт, традицияләрен өйрәтә. Нәниләр, өлкәннәр белән бергәләп, милли уенчыклар тегә, ясый, хезмәт күнекмәсен ала. Без килгәндә әти кеше нәниләргә борыслардан «өй салырга», «кое төзергә» өйрәтә иде. Музыка залында «Аулак өй» гөрли. Әбиләр һәм нәниләр татар, рус, мари, мордва халыкларының уеннарын уйнап, җырлап-биеп күңел ачты. Милләтләр дуслыгына нигез менә ничек салына ул. «Мөхтәрәм кунаклар» аллеясына туя агачлары утыртырга да өлгердек.

Татар мәдәният үзәгендә «Сөмбелә» бәйрәмен карап, тәҗрибә уртаклаштык. Бу бәйрәм соңгы елларда күз уңыннан төшеп калган иде. Эшебездә кулланырбыз, диештек. «Урама» фольклор ансамбле «Кыз елату» йоласын да күрсәтте. Кияүгә китәсе кыз кире кайтмас яшьлеге белән саубуллаша, ят гаиләгә килен булып төшә. Дуслары аны юатып, гаилә бәхете тели. Шулай итеп, «Урама» Сембер ягының бик борынгы кием үрнәкләрен, онытылып барган уен җырларын, әйтешләрен, биюләрен халыкка җиткерә. Шәһәрнең барлык иҗтимагый оешмалары һәр чараны бер йодрык булып, күмәк башкаралар. Өлкәнең милли-мәдәни автономиясе рәисе Рәмис Сафин, татар мәдәният үзәге җитәкчесе Рамилә Сафина, «Өмет» татар газетасы журналистларының эш-гамәлләрен күргәч, шундый фикер туа.

Әминә МӨХӘММӘТҖАНОВА.
Балтач

Хатирә

Минем әби каян белгән?

Белеме булмаса да, әбиемнең тумыштан килгән тоемлавы, үзен затлы итеп тота белүе бар иде. Кеше белән тавышланып йөргәнен, орышканын да хәтерләмим.

Бер мәлне шулай, миңа тугыз яшьләр тирәсе булгандыр, үземнән кечерәк күрше малаена нидер эшләдем инде. Хәзер юньләп хәтерләмим. Юк кына нәрсә булгандыр. Шук булсам да, махсус этлек эшли торганнардан түгел идем кебек. Ялгышып, уйламыйча зыян китергән булсам гына инде. Ул елап кереп китүгә, эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алып, тиз генә өйгә йөгереп кердем. Чөнки балаларының сүзен җөпләп, яклап, әти-әни янына керә торган гадәтләре бар иде күршеләрнең.

Әби ишегалдында кош-кортка җим биреп йөри. Минем кабалана-кабалана лапаска кереп бикләнгәнне күреп калды. «Ып» та итми, ярыктан карап басып торам. Йөрәгем бугазга тыгылды инде. Ул арада җилләп күрше малаеның әбисе килеп керде. Кызган тимергә басканмыни, күзләре ут чәчә.

– Кая әле ул, менә тегеләй, менә болай… – дип, мине сүгә, пыр туздыра. Әби елмаеп кына:

– Күрмәдем шул, өйдә күренмәде ул. Кайда йөридер… Әйе, шук инде, шук ул, – дип һәр сүзен җөпләп торгач, күрше әби тынычланды. Икәүләп авыл хәлләрен сөйләшеп, матур гына гәпләшеп китеп, хәйран вакыт тордылар. Үзара бик дус иде үзләре. Күрше чыгып киткәч, Саимә әби йомшак кына: «Чык, кызым», – дип килеп эндәште. «Шайтан кушып эшләгәндер, Ходай ярлыкар», – дип, һәр кешене гамәлләре, әйткән сүзе өчен аклый белә иде ул. Сүкмәде дә, үгетләмәде дә, үз эшләре белән мәшгуль булды.

Хәзер психологлар кешеләрне бу алымга махсус өйрәтә. «Психологик айкидо» дип атала ул. Ярсыткыч сүз ишетмәгәч, үзе тынычлана ул агрессор. Минем әби каян белгән икән ул хакта?

Безнең бик әләкләшәсе килсә дә, әнидән рөхсәт юк иде. Бер генә зарланып карадым. Әни: «Үзең өчен үзең тора бел, йөргән җиреңдә эшеңне бетереп кайт!» – диде, каты итеп. Шуннан соң әнигә моң-зарларны сөйләгән булмады. Үзем балаларымны, бер нәрсәләрен дә яшермичә, уртаклашырга өйрәттем. Кайчагында кылган гамәлләре ошарлык булмаса да, ачуланып гайрәтләрен кайтармадым. Булган хәлне сабыр гына уртага салып сөйләшә, кемнең хаклы, кемнең хаксыз булуын ачыклый идек. Хәзер дә балаларым кылган, кыласы гамәлләрен уртаклашып торалар.

Фирдәүсә БИКМӘТОВА

Фото бизәү өчен бирелде

ХА-ХА-ХАНӘ



Шушы урында көләсе

Язып алдык

Илсур Метшинның канатлы сүзләре

Илсур Рәис улы Метшин Казанны инде күп еллар җитәкли. Аның чыгышлары еш кына кызыклы образларга, чагыштыруларга, читләтеп әйтүләргә бай була. «Эшлекле дүшәмбе»ме ул яки берәр басмага интервьюмы – мэрның кайбер әйткән фикерләре канатлы сүз булып китәрлек. Әйдәгез, иң кызыклыларын барлыйк әле.

Шәһәрдәге иске агачлар карт акуланың тешләре сыман тырпаеп тора.

Бөтен хезмәткәр кар белән көрәшкә чыгарга тиеш. Эштә йоклагыз! Дөресрәге, йокламагыз!

Ливнёвкалар ул бит шәһәрнең кан тамырлары.

Иң яхшысына прәннек тоттырыгыз, иң начарына – көрәк.

Театр элгечтән башланган сыман, урамдагы ларёкларга карап, шәһәр турында фикер йөртәләр.

Кич белән әле иртә иде. Иртә белән инде соң. Безнең төн генә бар. Дөресрәге, көн.

Ашау-эчүне тиешенчә оештырыгыз. Әлеге чарада ач шофёрлар һәм полиция хезмәткәрләре булырга тиеш түгел.

Музейлар тузанга баткан булырга тиеш түгел.

Бер кризисны икенчесе белән чагыштырып булмый. Теш сызлауны тез авырту белән чагыштырып булмаган кебек. Монда төрле дару кирәк.

Ураза тотканымны белгәч, элек кешеләр миңа күзләрендә зур сорау билгесе белән карыйлар иде.

Арбаны аттан алда чаптырырга ярамый.

Милләтара татулык мәсьәләсе белән шөгыльләнмәсәк, ул үзе синең белән шөгыльләнә башлый.

Шуңа аптырыйм: мәктәпләрдә һаман да «кешеләр маймылдан туган» дип укыталар икән.

500 ел элек доллар да, евро да булмаган, ә халык бәхетле яшәгән.

Кар беткәч һәм сайлау алды кампаниясе тәмамлангач, ял итәрбез. Анысы да төгәл түгел.

Әз-мәз мәзәк

– Доктор, корсакны ничек бетерергә?
– Аркагыз белән борылыгыз.

* * *

– Матурым, бу кичәге ашмы әллә?
– Кичәге генә түгел, әле иртәгәге дә.

* * *

Без әкияткә таба барабыз. Тиздән һәр йомырка алтын булачак.

* * *

– Матурым, ә син миңа яратып өйләндеңме?
– Әлбәттә, яратып. Башкача бу адымны берничек тә аңлата алмыйм.

* * *

Урамда аккумулятор күтәргән мужикны күрсәгез, димәк, бүген салкын.

* * *

– Менә элек ничек иде?
– Ничек?
– Әйтмә дә!
– Ә хәзер ничек?
– Шул шул!

* * *

Айти-компаниягә җыештыручы апа кирәк. Карьера буенча үсеш гарантияләнә. Конференцияләрне тыңлау бушка.

* * *

– Без өйләнешкәч, бөтен шатлык һәм борчуларыбыз уртак булачак.
– Минем бернинди борчуларым да юк.
– Өйләнешкәч дим бит.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Хатирә

ҮЗЕМӘ ҮЗЕМ КЫЗЫК ТАБАМ

Мин яшь чагымда мәче булып кычкырырга ярата идем. Авылда безнең бер кара мәче бар иде. Ул шундый калын тавыш белән кычкыра, мияулый иде. Без аны күрше авылга да илтеп куеп карадык, ул, юлны табып, яңадан авылга кире кайтты.

Әти төнлә эштән кайтып, өйдә чәй эчеп утырганда, бервакыт түшәмнән ниндидер сыекча ага башлады. Әти, аптырап, чормага менеп караса, теге мәче шундагы пычкы чүбен казып, сиеп куйган да, шул әтинең чәенә агып төшкән иде. Без куркып, аптырап калган идек шул вакытта. Мәче шулай итеп әтидән үчен алды, без моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәдек.

Бервакыт мин өйдә караватта ятам. Теге мәче кебек: «Ха-пи-оооон!» – дип кычкырып, улап ук җибәрдем. «Теге тагын кайткан инде, тагын кычкыра, шуның тавышы!» – дип, әти белән энекәш карават асларыннан мәчене эзли башладылар. Мин аның саен мәче булып катырак улыйм, кычкырам, үзем тыела алмыйча көләм! Шунда әтиләр өйнең астын өскә китереп тә, мәчене тәки эзләп таба алмадылар.



Казанның Әмәт тавында дустым Рәшит яши. Үз өе белән торгач, бер елны мин аңа өй астын чистартырга булыштым. Әзрәк эшләгәч, мин мәче булып кычкыра башладым. Рәшитнең дә өендә мәчесе бар иде. «Ник әле генә ашаттым бит, чистый туймадың инде, нигә кычкырасың?!» – дип мәчесен сүгә, куа башлады бу. Идән астыннан карап торам, минем кычкырганга кая барырга белми, мәче үзе дә аптырады. Бер Рәшиткә, бер миңа карый! Рәшит барыбер мин кычкырганын сизмәде бит шул вакытта!

Бервакыт автобуста бакчадан кайтып барам. Минем яныма мәчесен кочаклаган бер хатын килеп утырды. И сөя, и ярата мәчесен. Мин башымны икенче якка бордым да мәче булып мияулап алдым. Теге хатын: «Чего, миленький, что случилось?» – дип мәчесенә текәлде. Мин әкрен генә һаман мияулавымны дәвам итәм. Теге хатын мәчесен нишләтергә белми, бер күтәрә, бер төшерә кулыннан. Миңа кызык, көләсе килә. Шулай итеп, юл буе үземә кызык табып кайткан идем ул елны да.

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН

Мач әйткән!

Раяз ФАСЫЙХОВ, җырчы:

– Ни өчен бөтен җырлар мәхәббәт турында? Чөнки безнең халык яратырга ярата.

Бәйрәм белән!

Хуш киләсең, Яңа ел!

«Әйдә, бу мәсьәләгә Яңа елдан соң кайтыйк әле» дигән сүзне куллана башласагыз була инде.

Быел хатны Кыш бабайга түгел, Кар кызына язам әле. Хатын-кыз хатын-кызны яхшырак аңларга тиеш.

Гаиләдә бөтен нәрсәне бергәләп эшләргә кирәк. Әйтик, хатын чыршы бизи, ә ир шул чыршы астына бүләкләр сала.

Менә инде декабрь уртасы җитте. Ә сез һаман: «Чыршыңны чыгарып ат инде», – дисез.

Якыннарыгыз белән бүгеннән үк үпкәләшә башласагыз, Яңа елга бүләк сатып аласы булмаячак. Соңгы көнгә калдырмагыз.

Декабрьдә шул ук проблемалар инде. Әмма тирә-юньдә гирляндалар яна.

Әгәр дә сиңа эштә: «Әйдә, Яңа елга кадәр эшләп бетерик инде шуны», – дип әйтәләр икән, димәк, аны син эшләргә тиеш буласың.

2024 елда леопард төсендәге кием кемнәргә килешәчәк? Бары тик леопардларга.

Шулай бервакыт

ХӨҖҖӘТ БЕЛӘН ЯППАР

Авылыбызның «Чат» дигән урыны бар. Ул дүрт урамның кибет, мәчет, клуб урнашкан җирендә. Авыл ирләре соңгы хәбәрләр белән танышу, ишетү өчен көн дә шунда җыелалар – шундый гадәткә күнегелгән. Көн әйбәт чагында – тышта, әгәр дә инде яңгыр-фәлән булса, кибеткә керәләр. Кибетче – Хәмит Зиннуры дип йөртәләр иде инде аны, бик тә гадел, абруйлы, үз эшен матур һәм яратып башкара торган абзый. Әйе, менә шунда кереп тулалар. Зиннур абый аларга бер сүз әйтми, тыныч кына ирләрнең авыл һәм дөнья хәлләрен сөйләшен тыңлап, эшләп утыра. Билгеле, кибетче хатын-кыз булса, анда җыела алмаслар иде, әхлак ягыннан да, гомумән, төрлечә уйласаң да, бер фикер – килешми. Еш кына ирләр арасында кызык кешеләр дә бар, алар байтак безнең авылда. Бу юлы иң кәттәләре – Яппар абый (ишле гаилә хуҗасы, ун кыз үстерде микән, төгәл белмим, хәер, үзе дә төгәл белмәгәндер), икенчесе – Хөҗҗәт абый (монысының да шул чама кызлары). Ишек төбенәрәк куелган зур казанны карап йөриләр болар эндәшмитынмый, кулларын артка куеп. Берәүнең дә боларда исләре юк. Ну, йөриләр... Йөрсеннәр, кемнең ни эше бар?.. Шул вакыт Хөҗҗәт абзый телгә килде дә:

– Карале, Хәмитов, бу колхоз өчен кайтарылган казаннарның зуррагы юк идемени? Безнең Яппар белән икебезнең гаилә өчен бәләкәйрәк булыр бу. Җитмәсә, берәү генә икән әле... – дип әйтеп куйды.

Ирләр, эчләре катып, тончыга-тончыга көләргә тотындылар.

Яппары:

– Хөҗҗәт, ал син моны сатып. Бер пешереп ашагач, миңа биреп торырсың, – дип, көлүчеләр ялкынына кислород сибеп алды.

Миннән кайвакыт сорыйлар:

– Сезнең авылда бөтенегез дә әллә шундыймы – синең кебек мәзәкчән? – дип. Менә хәзер аңладыгыз инде.

Алмаз ХӘМЗИН



Тормыштан

Көфер уйлар

✓ Эшкә контейнер белән азык йөртә башлауга, картлык килә.
✓ Сатучылар килеп ярдәм итәргә теләмәсә, кешеләр тауарларны теләбрәк сатып алыр иде.
✓ Тешләргә нервылар нигә кирәк? Нинди борчулары бар аларның?
✓ Сырхауханәдә иң куркынычы – чиратта синең алда торган кешенең югалуы һәм ул кемнән соң булганын берәүнең дә белмәве.
✓ Кар кешесе турында инде бер 20 еллап берни ишетелми. Исән-сау микән ул?
✓ Яңа кием аласың, бер атна киясең һәм тагын кияргә киемең юк!
✓ Бу дөньяда бөтен нәрсә оча ала. Әмма күпчелек әйберләр өстән аска гына.

УТ БЕТТЕ

Булган хәл. Казан дәүләт университеты. 1990 нчы еллар ахыры. Журналистика факультетының татар бүлегендә укучы студентларның күпчелеге – авыл балалары. Университет биналарында алган теорияне ныгыту өчен, уку программасында җәйге практика каралган. Журфак студенты өчен бу – гадәттә, туган ягына кайтып, район газетасында атна-ун көн каләм чарлап алу. Сентябрьдә шушы эш-гамәлләр буенча доцент һәм профессор абыйларыбыз каршында хисап тотасы.

Дәрес бара. Бер курсташыбыз такта янында чыгыш ясый:

– Быелгы җәйге практиканы мин район газетасында уздым. Беренче көнне фәлән авылга бардым. Фәлән апа белән интервью эшләдем. Газетада бастырдылар. Икенче көнне утырып мәкалә яздым. Өченче көнне редакциядә хатлар арададым. Аннары ут бетте.

Моңарчы студентны тыныч кына тыңлап утырган укытучы абзый аптырап китте:

– Ничек инде ут бетте?

– Шулай.

– Ну аннары утны биргәннәрдер бит?

– Әйе, берничә көннән бирделәр. Әмма практика көннәре беткән иде инде, – диде студент.

Бөтен аудитория шаркылдап көлде.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13596 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 367

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+